Такой подход в полной мере соотносится с правовой позицией Конституционного Суда Российской Федерации, который неоднократно указывал, что предложение об изменении места и (или) времени проведения публичного мероприятия обязательно должно быть мотивированным и вызываться либо необходимостью сохранения нормального и бесперебойного функционирования жизненно важных объектов коммунальной или транспортной инфраструктуры, либо необходимостью поддержания общественного порядка, обеспечения безопасности граждан (как участников публичного мероприятия, так и лиц, которые могут находиться в месте его проведения в определенное для этого время), либо иными подобными причинами (определения от 2 апреля 2009 года

№ 484-О-П, 1 июня 2010 года № 705-О-О, постановления от 18 мая 2012 года № 12-П, от 14 февраля 2013 года № 4-П).

Это согласуется также с общепризнанными принципами и нормами международного права, в том числе закрепленными в Международном пакте о гражданских и политических правах, статья 21 которого, признавая право на мирные собрания, допускает введение обоснованных его ограничений, налагаемых в соответствии с законом и необходимых в демократическом обществе в интересах государственной или общественной безопасности, общественного порядка, охраны здоровья и нравственности населения или защиты прав и свобод других лиц.

С учетом изложенного, часть 2 статьи 11 рассматриваемого Закона Республики Татарстан по своему содержанию и целевому предназначению направлена на защиту прав и свобод как лиц, участвующих в публичных мероприятиях, так и лиц, в них не участвующих, исходит из целей сохранения нормального и бесперебойного функционирования объектов транспортной инфраструктуры и обеспечения законности, правопорядка и общественной безопасности в целом и тем самым не нарушает права заявителя.

Таким образом, положения части 4 статьи 3 и части 2 статьи 11 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении условий реализации прав граждан на проведение собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан» не посягают на само существо права на свободу мирных собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований, не создают ограничений организации и проведению публичного мероприятия, участию в нем граждан и тем самым по своему содержанию, вопреки утверждению заявителя, не отменяют, не умаляют и иным образом не нарушают конституционные права человека и гражданина и не противоречат Конституции Республики Татарстан, в том числе ее статьям 28 (часть первая), 43, 48 (часть первая) и 58 (часть вторая).

4. Признание оспариваемых заявителем норм соответствующими Конституции Республики Татарстан не препятствует дальнейшему совершенствованию правового регулирования порядка подачи уведомления о проведении публичного мероприятия.

В целях обеспечения принципов юридического равенства и справедливости, а также более полного и оперативного информирования организатора публичного мероприятия о ранее поданных другими организаторами публичных мероприятий уведомлениях, Конституционный суд Республики Татарстан считает возможным установить на законодательном уровне порядок размещения такой информации на официальных сайтах соответствующих органов публичной власти в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» не только применительно к проведению публичных мероприятий в специально отведенных местах, как это закреплено в части 5 статьи 5 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении условий реализации прав граждан на проведение собраний, митингов, демонстраций, шествий и пике-

тирований в Республике Татарстан», но и при проведении их вне специально отведенных мест.

Данный подход корреспондирует правовой позиции Конституционного Суда Российской Федерации, согласно которой законодатель субъекта Российской Федерации при определении в соответствии с федеральным законодательством процедурных правил, касающихся подачи уведомления о проведении публичного мероприятия, может предусматривать дополнительные гарантии права на свободу мирных собраний, если это необходимо для его эффективной реализации в конкретных условиях (Постановление от 13 мая 2014 года № 14-П).

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, частями первой и второй статьи 66, статьями 68, 69, 71 и 73, пунктом 1 части первой статьи 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**п о с т а н о в и л :**

1. Признать часть 4 статьи 3 и часть 2 статьи 11 Закона Республики Татарстан от 25 декабря 2012 года № 91-ЗРТ «Об обеспечении условий реализации прав граждан на проведение собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан» соответствующими Конституции Республики Татарстан.

2. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

3. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 65-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**гражданин Г.З. Нуриәхмәт шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешенең һәм 11 статьясындагы 2 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2015 ел
1 декабрь
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясының беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешенең һәм 11 статьясындагы 2 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Г.З. Нуриәхмәтнең шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Р.Г. Сәхиева мәгълүматын, яклар — гражданин Г.З. Нуриәхмәт, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе Ш.Ш. Яһудин, Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары Р.И. Заһидуллин, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты хокук идарәсенең финанс һәм хезмәт законнары мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.В. Токмаков, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының автомобиль транспорты бүлеге әйдәүче киңәшчесе А.Н. Муллин аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге мөдире Д.И. Мәхмутовның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Та-

тарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе башлыгы А.А. Ощепковның, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең административ хокук һәм законнарны системалаштыру бүлекчәсе мөдире Д.Н. Латыпованың, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Р.С. Ибраһимовның, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы урынбасары Т.Р. Гыйззәтовның, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Г.С. Галимовның, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинованың чыгышларын тыңлап, суд утырышында тәрҗемәче — Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтының гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты Р.М. Болгарова катнашында, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлеше һәм 11 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Г.З. Нуриәхмәт шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләр администрацияләрендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган башкарма хакимият органында гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затлар һәм (яисә) структур бүлекчәләр билгеләнә. 11 статьяның дәгъва белдерелә торган 2 өлеше билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсе гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турындагы нигезләнгән тәкъдимне «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда гавами чаралар уздыру турын-

да хәбәрнамә бирелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтле башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан гавами чараны оештыручыга җиткерү өчен нигез була.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән күренгәнчә, гражданин Г.З. Нуриәхмәт, «Бөтентатар иҗтимагый үзәге» иҗтимагый оешмасының әгъзасы буларак, берничә тапкыр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына әлеге оешма тарафыннан митинглар һәм пикетлар формасында гавами чаралар уздыру турында белдерүләр биргән булган, аларны килештерүдән аңа баш тартылган, шул исәптән күрсәтелгән урыннарда башка гавами чараларның планлаштырылган булуы да сәбәп булган.

Мөрәҗәгать итүче үз шикаятендә шулай ук аның тарафыннан Солтангалиев мәйданында митинг уздыру турында белдерү бирелгән булуын күрсәтә, әмма, әлеге территориядә түләүле муниципаль парковка оештырылу сәбәпле, аны үткәрү рөхсәт ителмәгән. Шул ук вакытта, аның фикеренчә, парковка, автомобиль юлы өлеше буларак, транспорт инфраструктурасы объектларына керә, шуңа күрә дәгъвалана торган Законның 11 статьясындагы 2 өлешендә каралган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсе гавами чараны уздырудан баш тартуга нигез була ала. Әмма, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, әлеге бәяләмәнең эчтәлеге белән ул таныштырылмаган.

Гражданин Г.З. Нуриәхмәт фикеренчә, дәгъвалана торган закон нигезләмәләре килгән белдерүләрне җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары һәм (яисә) структур бүлекчәләре тарафыннан кабул итү һәм карау тәртибен, аерым алганда, гавами чараларны уздыру турындагы белдерүләрне карау өчен җаваплы булучыларны билгеләмиләр һәм гавами чараларны оештыручыларның андый чараларны уздыру турындагы элегрәк бирелгән белдерүләр белән танышып чыгу тәртибен, шул исәптән тиешле мәгълүматны гавами хакимият органнарының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, билгеләмиләр, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсен гавами чараны оештыручылар игътибарына хокукый җиткерү механизмын күздә тотмыйлар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Г.З. Нуриәхмәт Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Рес-

публикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешен һәм 11 статьясындагы 2 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш), 43, 48 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; Татарстан Республикасында гражданнар закон нигезендә тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлаулар уздырырга хокуклы; һәркем теләсә нинди законлы ысул белән ирекле рәвештә мәгълүмат эзләргә, алырга, тапшырырга, әзерләргә һәм таратырга хокуклы; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлеше һәм 11 статьясындагы 2 өлеше әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны һәм хокук тәртибен, җәмәгать иминлеген тәэмин итү Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагына керә (72 статья, 1 өлешнең «б» пункты). Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителүче законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруны хокукый җайга салу «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башкарыла. Әлеге Федераль законда каралган очракларда җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру шартларын тәэмин итүгә кагылышлы норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте чыгара, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары кабул итә һәм чыгара (1 статьяның 1 өлеше).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясының 2 пункты нигезендә шул исәптән Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм

пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Конституциясе билгеләгән Россия Федерациясе һәм аның субъектларының карамагындагы мәсьәләләрне бүлешүгә нигезләнеп эш иткән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештә 75 статьясы (2 пункт) һәм 29 (өченче өлеш), 43 статьялары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен законлы гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 43 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнар закон нигезендә тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлаулар уздырырга хокуклы. Әлеге норма Россия Федерациясе Конституциясенең асылы буенча тиңдәш булган 31 статьясы нигезләмәләренә тәңгәл килә.

Россия Федерациясе гражданнарының тыныч җыелышлар ирегенә хокукларын гамәлгә ашыруын тәэмин итү максатыннан федераль закон чыгаручы «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында»гы Федераль законда гавами чаралар оештыру һәм уздыру тәртибе нигезләрен регламентлаштыра.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясеннән күренгәнчә, «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында»гы Федераль законда гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирүгә кагылышлы төп таләпләрне (гомуми нигезләрне) генә күздә тотып, федераль закон чыгаручы хәбәрнамә бирү тәртибе Россия Федерациясе субъектларының законнары дәрәҗәсендә җентекләп регламентлаштырылырга тиеш дигәннән чыгып эш иткән, шуның өстәвенә алар тарафыннан кертелә торган оештыру-процедура механизмнары төрле булырга мөмкин, ләкин һәр очракта, Россия Федерациясе Конституциясе тарафыннан танылган тыныч җыелышлар ирегенә хокук иллюзор булмасын өчен, бу өлкәдәге хокукый җайга салуның әйтелгән Федераль законның преамбуласында чагылган билгеләнешенә, атап әйткәндә, Россия Федерациясе Конституциясе билгеләгән Россия Федерациясе гражданнарының тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлаулар уздыруга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә җавап бирергә һәм гавами чаралар уздыручыларга хәбәрнамә бирү срокларына караган норматив таләпләр үтәлешенең реаль мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш (2014 елның 13 маендагы 14-П номерлы Карар).

3.1. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән тыныч җыелышлар ирегенә хокукның гамәлгә ашыру механизмының әһәмиятле элементларының берсе булып аталган Федераль законның 7 статьясы белән каралган тәртиптә гавами чара оештыручының Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органына яисә җирле үзидарә органына гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирү бурычы тора. Әлеге статьяның

2 өлеше белән каралганча, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органына яисә җирле үзидарә органына гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе Россия Федерациясе субъектының тиешле законы белән регламентлаштырыла.

Бирелгән дискрецион вәкаләтләр чикләрендә, гавами чараның уздырылу урынына карап, республика закон чыгаручысы шундый тәртипне дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләде, аның 1, 2 һәм 3 өлешләре эчтәлегеннән аңлашылганча, гавами чара уздыру турындагы хәбәрнамә язма формада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган башкарма хакимият органына яисә муниципаль берәмлек администрациясенә (алга таба — вәкаләтле орган) бирелә. Монда әлеге тәртип элементларының берсе булып вәкаләтле органның карала торган статьяның 4 өлешендә каралган гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затлар һәм (яисә) структур бүлекчәләрне билгеләү бурычы тора.

Үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган җайга салу гавами чаралар уздыруны хабәрнамә бирү тәртибендә үтәү буенча таләпләрне тәэмин итүгә, шулай ук гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне кабул итү һәм карау функцияләрен үти торган органны билгеләүгә юнәлтелгән.

Казан шәһәрендә гавами чаралар үткәрү турындагы хәбәрнамәләрне карау тәртибе «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне карау тәртибе турында» 2015 елның 12 октябрендәге 3713 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән регламентлаштырылган, аның нигезләмәләре үзләренең мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча элек гамәлдә булган 2007 елның 20 мартындагы 448 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карарының нигезләмәләренә тәңгәл килә. 2015 елның 12 октябрендәге 3713 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 1 пунктындагы 1.1.3 пунктчасы нигезендә Казан шәһәрендә гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәне карау һәм аның буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле вәкилен билгеләү Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара эшләү бүлеге тәкъдиме буенча әлеге орган Аппараты җитәкчесенең язма күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.

Гавами чара уздыру турындагы хәбәрнамәне карау өчен җаваплы конкрет вазыйфаи затның һәм (яисә) структур бүлекчәнең дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законында түгел, ә законга буйсынулы норматив хокукый актта билгеләнү факты кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый, чөнки Россия Федерациясе Конституция Судының 2006 елның 12 июлендәге 378-О номерлы Билгеләмәсендә бәян ителгән хокукый позициясенең

мәгънәсе буенча законга буйсынулы акт закон чыгаручы дәрәҗәсендә беркетелгән нигезләмәне бары тик конкретлаштыра, ә норманың бланкет характеры үзеннән-үзе аның конституциячел булмавы турында расламый, — мондый күрсәтмәләрнең конституциячел-хокукый мәгънәсе аларның гамәлдә булган хокукый актлар системасындагы билгеләнешеннән чыгып ачыклана.

Димәк, дәгъвалана торган нормада күрсәтелгән хокукый җайга салу белән система бердәмлегендә гражданнарның тыныч җыелышлар ирегенә конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен нинди дә булса чикләүләр юк. Моннан тыш, җирле үзидарә органнарының гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне кабул итү өчен җаваплы конкрет вазыйфаи затларын һәм (яисә) структур бүлекчәләрен закон чыгаручы дәрәҗәсендә беркетү Татарстан Республикасы закон чыгаручысының җирле үзидарә органнары компетенциясенә ярамый торган катышуы булыр иде һәм шуның белән җирле үзидарә мөстәкыйльлеге конституциячел принцибын бозуга китерер иде.

Мөрәҗәгать итүченең дәгъвалана торган нормада бер үк урында һәм бер үк вакытта охшаш чаралар уздыру турындагы элегрәк бирелгән хәбәрнамәләр белән гавами чаралар оештыручыларның танышып чыгу тәртибен билгели торган нигезләмәләрнең булмавы турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында»гы Федераль закон андый хокукый җайга салуны билгеләүне күздә тотмый, шулай ук Россия Федерациясе субъектының закон чыгаручысына карата аны регламентлаштыру кирәклеге турындагы күрсәтмәләрне үз эченә алмый, дип билгеләп үтә.

Шул ук вакытта республика закон чыгаручысы хокук иҗаты буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында махсус бирелгән урыннарда гавами чаралар уздыру турында гавами чаралар оештыручылар тарафыннан бирелгән хәбәрнамәләр хакында гражданнарга белдерү тәртибен билгели. Шулай, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 5 өлеше нигезендә махсус бирелгән урыннарда гавами чаралар уздыру турында гавами чараларны оештыручылар тарафыннан бирелгән хәбәрнамә хакындагы мәгълүмат, гавами чараларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, хәбәрнамә алынган көнне гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә бирелгән вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла. Китерелгән хокукый җайга салу дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлеше нигезендә гавами чараларның, кагыйдә буларак, махсус бирелгән урыннарда уздырылуына бәйле.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткән турыдан-туры дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешендә гавами чаралар оештыручылар тарафыннан бирелгән

хәбәрнамәләр хакында гражданнарга белдерү тәртибенең җайга салынмавы үзеннән-үзе гражданнарның тыныч кына, коралсыз килеш җыелырга, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздырырга хокукларын бозу дип карала алмый.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлеше нигезләмәләре һәм вәкаләтле орган тарафыннан расланган гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне карау тәртибе юридик көче алар бергә кулланылганда гына гамәлгә ашырыла торган бердәм нормалар комплексын тәшкил итә һәм шуның белән кеше һәм гражданның, шул исәптән гражданин Г.З. Нуриәхмәтнең дә, конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый.

3.2. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» Федераль законның 8 статьясындагы 3.1 өлешенең нигезләмәләре эчтәлегеннән аңлашылганча, гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган һәм гавами чара уздыру тыелган урыннарга карамаган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе әлеге Федераль закон таләпләрен һәм федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган транспорт иминлеген һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектының законы белән билгеләнә.

Күрсәтелгән тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясында регламентлана. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чараны оештыручы гавами чара (җыелыштан һәм бер катнашучы тарафыннан уздырыла торган пикеттан гайре) уздыру турындагы хәбәрнамәне югарыда аталган Федераль законда билгеләнгән срокларда вәкаләтле органга язма рәвештә җибәрә. Күрсәтелгән статьяның 3 һәм 4 өлешләре буенча вәкаләтле орган, гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында (алга таба — транспорт инфраструктурасы объектлары) гавами чара уздырылу турында хәбәрнамә алганнан соң, хәбәрнамәнең күчермәсен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органына җибәрә, аны карау нәтиҗәсе буенча ул транспорт инфраструктурасы объектында гавами чара уздыру мөмкинлеге турында дәлилләнгән бәяләмә белән бергә, шул исәптән транспорт инфраструктурасы субъекты фикерен исәпкә алып, рәсми җавап бирә.

Шул ук вакытта республика закон чыгаручысы транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләрнең тулы исемлеген билгеләгән. Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясының 1 өлеше нигезендә Татарстан Республика-

сы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсе түбәндәге очракларда бирелә: транспорт инфраструктурасы объекты авария хәлендә булса һәм аның территориясендә гавами чара уздыру гавами чарада катнашучыларның сәламәтлегенә һәм иминлегенә куркыныч тудырса; гавами чара планлаштырыла торган мизгелгә транспорт инфраструктурасы объектында ремонт эшләре башкарылса; гавами чара уздыру гражданнарның транспорт инфраструктурасы объектыннан файдалануына каршылык (чикләү) тудырса яисә транспорт инфраструктурасы объектларында транспорт чаралары хәрәкәтен тулысынча туктатуны таләп итсә.

Күрсәтелгән бәяләмә, әлеге статьяның дәгъвалана торган 2 өлеше нигезендә, гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турындагы нигезләнгән тәкъдимне гавами чаралар уздырылу турындагы хәбәрнамә бирелә торган вәкаләтле орган тарафыннан гавами чараны оештыручыга җиткерү өчен нигез булып тора.

Китерелгән хокукый җайга салуның мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсе әлеге чараны оештыручы тарафыннан күрсәтелгән урында һәм (яисә) вакытта гавами чара уздыруны килештерүдән баш тарту өчен нигез булып тора. Димәк, андый бәяләмәдә гавами чараны уздыруга каршы килә торган барлык хәлләр тулысынча күрсәтелгән булырга тиеш.

Гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы эчтәлеге һәм конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлеше билгеләгәнчә, транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруны килештерүдән баш тарткан очракта, аны уздыру турында хәбәрнамә бирелгән вәкаләтле орган гавами чараны оештыручыга күрсәтелгән бәяләмәнең булуы турында гына түгел, ә аталган гавами чараны килештерүдән баш тартуга нигез булган гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләрне күрсәтеп, эчтәлеген дә җиткерергә бурычлы. Шул ук вакытта гавами чара уздыруны килештерүдән баш тарту турындагы карар асылда тигезлек һәм закон өстенлеге, гаделлек, гражданнарның законга һәм дәүләтнең гамәлләренә ышанычын саклау принципларының бозылуына китермәскә тиеш.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турындагы тәкъдим һичшиксез дәлилләнгән булырга һәм коммуналь яки транспорт инфраструктурасының тормыш өчен әһәмиятле объектларының нормаль һәм өзлексез кулланылышын саклауның кирәклеге белән, яисә җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарның (гавами чарада катнашучыларның да,

билгеләнгән вакытта аны уздыру урынында булырга мөмкин затларның да) иминлеген тәэмин итү кирәклеге белән, яисә башка шуның ише сәбәпләр белән нигезләнгән булырга тиеш (2009 елның 2 апрелендәге 484-О-П номерлы, 2010 елның 1 июнендәге 705-О-О номерлы, 2012 елның 18 маендагы 12-П номерлы, 2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы карарлар).

Бу шулай ук халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормаларына туры килә, шул исәптән Гражданлык һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактта каралганнарына да, аның 21 статьясы, тыныч җыелырга хокукны танып, закон нигезендә һәм демократик җәмгыятьтә кирәкле дәүләт яки җәмәгать иминлеге, җәмәгать тәртибе, халыкның сәламәтлеген һәм әхлагын саклау яки башка затларның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәнфәгатьләрендә аны нигезле чикләүләрнең кертелүенә юл куя.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, карала торган Законның 11 статьясындагы 2 өлеше үзенең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча гавами чараларда катнашучы затларның да, аларда катнашмаучы затларның да хокукларын һәм ирекләрен яклауга юнәлгән, транспорт инфраструктурасы объектларының нормаль һәм өзлексез кулланылышын саклау һәм гомумән законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларыннан чыга һәм шуның белән мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозмый.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлеше һәм 11 статьясындагы 2 өлешенең нигезләмәләре тыныч җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру иреге хокукының асылына каршы төшмиләр, гавами чара оештыруга һәм уздыруга, анда гражданнарның катнашуына чикләүләр куймыйлар һәм шуның белән эчтәлекләре буенча, мөрәҗәгать итүченең раславына карамастан, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, шул исәптән аның 28 (беренче өлеш), 43, 48 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килмиләр.

4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килгәнлеген тану гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибен хокукый җайга салуны киләчәктә камилләштерүгә комачауламый.

Юридик тигезлек һәм гаделлек принципларын тәэмин итү, шулай ук гавами чара оештыручыга башка гавами чараларны оештыручылар тарафыннан элегрәк бирелгән хәбәрнамәләр турында тулырак һәм оперативрак белгертү максатларында, Татарстан Республикасы Конституция суды закон чыгаручы дәрәҗәсендә андый мәгълүматны, «Татарстан Республикасын-

да гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 5 өлеше билгеләгәнчә, гавами чараларны махсус бирелгән урыннарда уздыруга карата гына түгел, ә аларны махсус бирелгән урыннардан читтә уздырганда да тиешле гавами хакимият органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыруны кирәк дип таба.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, аның нигезендә Россия Федерациясе субъектының закон чыгаручысы, гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирүгә кагылышлы процедура кагыйдәләрен федераль законнар нигезендә билгеләгәндә, тыныч җыелышлар ирегенә хокукны конкрет шартларда эффектив тормышка ашыру өчен кирәк булса, әлеге хокукның өстәмә гарантияләрен күздә тота торган нормаларны кабул итә ала (2014 елның 13 маендагы 14-П номерлы Карар).

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясының беренче өлешендәге 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешен һәм 11 статьясындагы 2 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 65-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.А. Косуровой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом «с» Перечня органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210**

2 июля
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.Ф. Гафиятуллина, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки А.А. Косуровой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан 23 апреля 2015 года обратилась гражданка А.А. Косурова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом «с» Перечня органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка А.А. Косурова обратилась в отдел социальной защиты Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в Советском районе муниципального образования города Казани с заявлением о присвоении ей звания «Ветеран труда», так как у нее имеются необходимый для этого трудовой стаж, а также награды Центрального Комитета Всесоюзного Ленинского Коммунистического Союза Молодежи (далее — ЦК ВЛКСМ) — знак «Ударник-73» и значок «Молодой передовик производства». Однако заявительнице было отказано в приеме документов на присвоение указанного звания, поскольку Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодежи (далее — ВЛКСМ) был общественной организацией, не участвовавшей в осуществлении государственных (ведомственных) функций, а

учрежденные им награды не являются основанием для присвоения звания «Ветеран труда». Не согласившись с данным отказом, гражданка А.А. Косурова обратилась в Ново-Савиновский районный суд города Казани, который решением от 25 декабря 2014 года, оставленным в силе апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан от 12 марта 2015 года, отказал ей в удовлетворении исковых требований о признании права на присвоение звания «Ветеран труда».

По мнению заявительницы, признание ВЛКСМ общественной организацией, не участвовавшей в осуществлении государственных (ведомственных) функций, не является правомерным. В обоснование своей позиции она ссылается на положения Устава ВЛКСМ, принятого XIV съездом ВЛКСМ, согласно которым ВЛКСМ наряду с осуществлением иной деятельности участвует в управлении государственными и общественными делами, в решении политических, хозяйственных и социально-культурных вопросов, пользуется правом законодательной инициативы в лице своих общесоюзного и республиканских органов.

Заявительница также указывает, что в соответствии с Перечнем ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденным приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481, ветеранами труда могут стать лица, награжденные нагрудными знаками, знаками отличия «Победитель социалистического соревнования ... года» Центрального Комитета КПСС, Совета Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ, а также «Ударник ... пятилетки» Центрального Комитета КПСС, Совета Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ (пункт 3).

Как отмечает гражданка А.А. Косурова, утвержденный постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210 Перечень государственных органов и организаций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, не содержит такого органа, как ЦК ВЛКСМ. Подобная непоследовательность правового регулирования, по ее мнению, приводит к тому, что одни знаки отличия, выдаваемые ЦК ВЛКСМ, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда», а другие награды ЦК ВЛКСМ — знак «Ударник-73» и значок «Молодой передовик производства» — не включены в Перечень ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденный приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481.

На основании изложенного гражданка А.А. Косурова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт «с» Перечня органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, централь-

ных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210, не соответствующим статьям 13, 28, 29 (часть первая), 54 (части первая и вторая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Во исполнение части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания "Ветеран труда"» принято постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210, которым утверждены Положение о порядке и условиях отнесения органов государственной власти и иных государственных органов, а также центральных органов общественных объединений и организаций к перечню органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, а также Перечень органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральных органов общественных объединений, организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан.

Из содержания части 2 статьи 1 вышеуказанного Закона Республики Татарстан следует, что для отнесения наград центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации к ведомственным знакам отличия в труде необходимо наличие двух, находящихся в неразрывном единстве, условий: во-первых, награды должны быть учреждены за заслуги и достижения в труде, а во-вторых, учредившие награды общественные объединения и организации должны участвовать в осуществлении государственных (ведомственных) функций.

Вопрос, касающийся отнесения к ведомственным знакам отличия в труде наград центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, которые участвуют (участвовали) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан.

Согласно правовой позиции, выраженной Конституционным судом Республики Татарстан в постановлении от 25 марта 2014

года № 58-П, установление условия об отнесении к ведомственным знакам отличия в труде наград центральных органов только тех общественных объединений и организаций, которые участвуют (участвовали) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, производно от публично-правовой природы отношений, связанных с присвоением звания «Ветеран труда», поскольку присвоение лицу данного звания влечет возникновение обязанности соответствующего государственного органа по предоставлению ветерану труда мер социальной поддержки, финансируемых за счет средств бюджета. Тем самым установленное республиканским законодателем условие отнесения наград центральных органов общественных объединений и организаций к числу ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых для присвоения звания «Ветеран труда», не может рассматриваться как нарушающее конституционный принцип равенства, поскольку данное условие основано на учете объективно существующих различий между общественными объединениями и организациями, вносящими (вносившими) свой вклад в осуществление государственных (ведомственных) функций, и теми из них, которые не участвуют (не участвовали) в данной деятельности. При этом Конституционный суд Республики Татарстан указал, что правомочие на участие в осуществлении общественными объединениями и организациями государственных (ведомственных) функций должно быть закреплено не только в уставах этих общественных объединений и организаций, но и в нормативных правовых актах, принятых органами государственной власти и определяющих статус соответствующих общественных объединений и организаций.

Данная правовая позиция, подтвержденная в определениях Конституционного суда Республики Татарстан от 8 апреля 2014 года № 8-О и от 21 мая 2015 года № 4-О, сохраняет свою силу.

Согласно оспариваемому заявительницей пункту «с» Перечня органов государственной власти и иных государственных органов СССР, РСФСР, Российской Федерации, центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210, центральные органы общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующие (участвовавшие) в осуществлении отдельных государственных (ведомственных) функций, относятся к органам, ведомственные знаки отличия в труде которых, учрежденные за заслуги и достижения в труде, учитываются при присвоении звания «Ветеран труда». Тем самым обжалуемая норма в части отнесения наград центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации к ведомственным знакам

отличия в труде не устанавливает каких-либо дополнительных требований и, по сути, воспроизводит положение части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”». Вместе с тем во исполнение пункта 2 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 марта 2012 года № 210 приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 29 июня 2012 года № 481 утвержден Перечень ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда» в Республике Татарстан, включающий в себя в том числе награды центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации, участвующих (участвовавших) в осуществлении отдельных государственных (ведомственных) функций. При этом данный Перечень не является исчерпывающим и отсутствие в нем какой-либо награды не может быть единственным и достаточным основанием для отказа в присвоении звания «Ветеран труда», поскольку правоприменителю необходимо установить, участвовало ли общественное объединение и организация в осуществлении государственных (ведомственных) функций и учреждена ли награда за заслуги и достижения в труде.

Следовательно, оспариваемая норма не сужает круг лиц, имеющих право на присвоение звания «Ветеран труда», не препятствует отнесению наград центральных органов общественных объединений и организаций СССР, РСФСР, Российской Федерации к ведомственным знакам отличия в труде и не может рассматриваться как нарушающая конституционные права и свободы человека и гражданина и, тем самым, не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки А.А. Косуровой не является допустимой.

Разрешение же вопросов о том, участвовал ли ВЛКСМ в осуществлении государственных (ведомственных) функций, учреждены ли имеющиеся у заявительницы награды ЦК ВЛКСМ — знак «Ударник-73» и значок «Молодой передовик производства» — за заслуги и достижения в труде, равно как и оценка законности и обоснованности правоприменительных решений по ее делу, в том числе с точки зрения правильности применения правовых норм с учетом фактических обстоятельств, не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, частью первой статьи 46, частями первой и пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

2. Согласно статье 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан и части пятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан по жалобам на нарушение конституционных прав и свобод граждан проверяет конституционность закона Республики Татарстан или его отдельных положений, нормативных правовых актов Президента и Кабинета Министров Республики Татарстан, а также органов местного самоуправления. Правила предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации целевой программы «Обеспечение жильем молодых семей в городе Казани» на 2014—2015 годы, утвержденные постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 9 июня 2014 года № 3094, соответствуют категории нормативных правовых актов, подведомственных Конституционному суду Республики Татарстан, и оспариваемые заявителем абзацы первый, второй и пятый пункта 22 указанных Правил могут быть рассмотрены на предмет их соответствия Конституции Республики Татарстан. Правила предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации подпрограммы «Обеспечение жильем молодых семей в Республике Татарстан на 2014—2015 годы» государственной программы «Обеспечение качественным жильем и услугами жилищно-коммунального хозяйства населения Республики Татарстан на 2014—2020 годы», утвержденные постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 30 апреля 2014 года № 289, также соответствуют категории нормативных правовых актов, подведомственных Конституционному суду Республики Татарстан, и абзацы первый, второй и пятый пункта 21 данных Правил могут быть рассмотрены на предмет их соответствия Конституции Республики Татарстан.

В соответствии с частью первой статьи 100 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» правом на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан с жалобой на нарушение конституционных прав и свобод обладают граждане, права и свободы которых нарушены законом Республики Татарстан, нормативными правовыми актами Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан, органов местного самоуправления, и их объединения.

При этом статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» установлено, что жалоба на нарушение конституционных прав и свобод законом Республики Татарстан или иным нормативным правовым актом допустима, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан; закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в

суде или ином органе. В этой связи приложенные к жалобе гражданина А.Ф. Шигапова копии писем из администрации Кировского и Московского районов Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 9 июля 2014 года, от 24 октября 2014 года и от 30 октября 2014 года могут рассматриваться как подтверждающие применение обжалуемых положений нормативных правовых актов при разрешении конкретного дела заявителя.

Тем самым жалоба гражданина А.Ф. Шигапова в части проверки конституционности абзацев первого, второго и пятого пункта 22 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации целевой программы «Обеспечение жильем молодых семей в г. Казани» на 2014—2015 годы, утвержденных постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 9 июня 2014 года № 3094, а также абзацев первого, второго и пятого пункта 21 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации подпрограммы «Обеспечение жильем молодых семей в Республике Татарстан на 2014—2015 годы» государственной программы «Обеспечение качественным жильем и услугами жилищно-коммунального хозяйства населения Республики Татарстан на 2014—2020 годы», утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 30 апреля 2014 года № 289, подведомственна Конституционному суду Республики Татарстан, исходит от надлежащего заявителя, соответствует критериям ее допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», и не содержит каких-либо оснований для отказа в принятии ее к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

3. Оспариваемый заявителем подпункт «б» пункта 23 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации целевой программы «Обеспечение жильем молодых семей в городе Казани» на 2014—2015 годы, утвержденных постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 9 июня 2014 года № 3094, устанавливает, что основанием для снятия молодой семьи с учета в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий для участия в Программе является утрата одного из оснований, дающих молодой семье право на получение социальной выплаты, предусмотренных пунктом 5 этих же Правил, в том числе достижение 36-летнего возраста одного из супругов либо одного родителя в неполной семье.

Конституционный Суд Российской Федерации неоднократно отмечал, что ограничение по возрасту, который для каждого из супругов не должен превышать 35 лет на день принятия решения органом исполнительной власти субъекта Российской Федерации о включении молодой семьи в список претендентов на получение социальной выплаты, нельзя расценивать как нарушение конституционных прав граждан (определения от 27 мая 2010 года № 738-О-О, от 19 октября 2010 года № 1333-О-О).

Кроме того, поставленный заявителем вопрос о правомерности снятия молодой семьи с учета в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий и утраты права на получение социальной выплаты при достижении 36-летнего возраста одного из супругов либо одного родителя в неполной семье уже был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. В определении от 15 июля 2013 года № 7-О Конституционный суд Республики Татарстан указал, что по своему содержанию и правовому смыслу положение о предельном возрасте в качестве необходимого условия для предоставления социальных выплат на приобретение жилья в рамках соответствующей муниципальной программы аналогично положению, закрепленному подпунктом «а» пункта 6 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение (строительство) жилья и их использования, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 17 декабря 2010 года № 1050, согласно которому возраст каждого из супругов либо одного родителя в неполной семье на день принятия органом исполнительной власти субъекта Российской Федерации решения о включении молодой семьи-участницы подпрограммы в список претендентов на получение социальной выплаты в планируемом году не превышает 35 лет.

Из этого следует, что проверка конституционности оспариваемого заявителем нормативного положения фактически означала бы оценку указанной нормы федерального законодательства на ее соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

Таким образом, оспариваемое положение, устанавливающее ограничение по возрасту супругов в молодой семье, не содержит неопределенности в вопросе о соответствии Конституции Республики Татарстан, и в силу этого жалоба заявителя в данной части не может быть признана допустимой.

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, пунктом 1 части второй статьи 39, статьей 42, частями первой и второй статьи 45, пунктом 2 части первой статьи 46, частью первой статьи 51, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Принять к рассмотрению жалобу гражданина А.Ф. Шигапова в части, касающейся проверки конституционности абзацев первого, второго и пятого пункта 22 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации целевой программы «Обеспечение жильем молодых семей в городе Казани» на 2014—2015 годы, утвержденных постановлением Исполнительного комитета муниципального образо-

вания города Казани от 9 июня 2014 года № 3094, а также абзацев первого, второго и пятого пункта 21 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации подпрограммы «Обеспечение жильем молодых семей в Республике Татарстан на 2014—2015 годы» государственной программы «Обеспечение качественным жильем и услугами жилищно-коммунального хозяйства населения Республики Татарстан на 2014—2020 годы», утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 30 апреля 2014 года № 289.

2. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.Ф. Шигапова в части, касающейся проверки конституционности подпункта «б» пункта 23 Правил предоставления молодым семьям социальных выплат на приобретение жилья в рамках реализации целевой программы «Обеспечение жильем молодых семей в городе Казани» на 2014—2015 годы, утвержденных постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 9 июня 2014 года № 3094, поскольку в этой части она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой.

3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

4. О принятом решении уведомить стороны — гражданина А.Ф. Шигапова, Кабинет Министров Республики Татарстан и Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

5. Назначить судьей-докладчиком по данному делу судью Конституционного суда Республики Татарстан А.Р. Шакараева.

6. Дату рассмотрения настоящего дела Конституционным судом Республики Татарстан установить в порядке очередности слушания дел в заседаниях Конституционного суда Республики Татарстан.

7. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 7-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 22 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацлары һәм 23 пунктындагы «б» пунктчасы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.Ф. Шиһаповның шикаяте буенча**

2015 ел
4 сентябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.Ф. Шиһаповның шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына 2015 елның 11 июнендә гражданин А.Ф. Шиһапов Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 22 пунктындагы беренче һәм бишенче абзацлары һәм 23 пунктындагы «б» пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Кагыйдәләрнең 22 пунктындагы дәгъвалана торган нигезләмәләре белән шул билгеләнгән:

— Казан шәһәре Башкарма комитеты районы(-нары) администрациясе ел саен 1 августтан 1 сентябрьгә кадәр 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында (алга таба шулай ук — Программа) катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә торучы яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуларын тикшерүне уздыра (беренче абзац);

— ел саен уздырыла торган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуны тикшерү яки кабаттан ачыклау вакытында яшь гаилә Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуын расламаса һәм (яки) яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру өчен берәр нигез ачыкланса, Казан шәһәре Башкарма комитеты районы(-нары) администрациясе шундый тикшерү тәмамланган яки тиешле нигезләр ачыкланган көннән алып 30 көн эчендә яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру турында карар кабул итә. Яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру турындагы карарда шундый исәптән төшереп калдыру нигезләре күрсәтелгән булырга тиеш. Яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру турындагы карар үзенә карата андый карар кабул ителгән яшь гаиләгә карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә бирелә яки юллана (бишенче абзац).

Кагыйдәләрнең 23 пунктындагы дәгъвалана торган «б» пунктчасы яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру нигезе итеп Кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган яшь гаиләгә социаль түләү алуга хокук бирә торган нигезләмәләрнең берсенең юкка чыгуын, шул исәптән ир белән хатынның берсенең яки тулы булмаган гаиләдәге ата-ананың берсенең 36 яшькә җитүен күздә тота.

2015 елның 23 июнендә гражданин А.Ф. Шиһаповтан шикаятькә өстәмә килде, анда ул үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләренең шулай ук Кагыйдәләрнең 22 пунктындагы икенче абзацы белән бозылганын күрсәтә, аның нигезендә яшь гаилә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуын раслар өчен, 1 августка кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты районы(-нары) администрациясенә Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «г» һәм «ж» пунктчаларында, шулай ук Кагыйдәләрнең 5 нче кушымтасындагы 3, 4, 11, 13—17 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыра. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Кагыйдәләрнең 22 пунктындагы аның тарафыннан дәгъвалана торган беренче, икенче һәм бишенче абзацларының нигезләмәләре мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча тиңдәш булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацлары нигезендә кабул ителгән.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм аларга кушып бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең гаиләсе 2009 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкар-

ма комитеты җитәкчесенең 2007 елның 18 июлендәге 1788 номерлы карары белән расланган 2008—2010 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы буенча субсидия алу өчен документлар тапшырган. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров районы администрациясенең яшь гаиләләр өчен торак программаларын гамәлгә ашыру буенча комиссиясе 2009 елның 23 декабрендәге утырышында мөрәҗәгать итүченең гаиләсен 2002—2010 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак һәм 2002—2010 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак алырга бирелә торган социаль түләү күләменнән арта торган хисапланган (уртача) торак бәясенең өлешен түләү өчен җитәрлек керемнәргә яки башка акчаларга ия буларак тану турындагы карарлар кабул итә. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров районы администрациясе башлыгының 2010 елның 11 гыйнварындагы 1р номерлы күрсәтмәсе белән А.Ф. Шиһапов гаиләсе өч кеше составында 2008—2010 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучы яшь гаиләләр исемлегенә кертелгән булган.

Әмма Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясенең яшь гаиләләр өчен торак программаларын гамәлгә ашыру буенча комиссиясенең 2013 елның 7 августындагы карары нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгының 2013 елның 15 августындагы 816ра номерлы күрсәтмәсе белән мөрәҗәгать итүченең гаиләсе, яңадан теркәлүне узу максатында, 2011—2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасында катнашучы яшь гаиләләр исемлегеннән гражданин А.Ф. Шиһаповның яше 35 тән арту һәм исәп нормасыннан күбрәк гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителү сәбәпле төшереп калдырылган.

Татарстан Республикасы Югары судының 2014 елның 27 мартындагы апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган Казан шәһәре Киров район судының 2013 елның 23 декабрендәге карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгының 2013 елның 15 августындагы 816ра номерлы күрсәтмәсе законсыз дип танылган, ә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгына мөрәҗәгать итүченең гаиләсен 2011—2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасында катнашучы яшь гаиләләр исемлегендә торгызу бурычы йөкләнгән.

Күрсәтелгән суд карарлары нигезендә гражданин А.Ф. Шиһапов гаиләсе 2011—2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасында катнашучы яшь гаиләләр исемлегендә торгызылган. Шул ук вакытта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрация-

се башлыгының беренче урынбасары хатында шул күрсәтелгән: «2012—2015 елларга “Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасы турында» 2011 елның 12 декабрендәге 8035 номерлы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныла һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасы раслана. Монда мөрәҗәгать итүчедән Кагыйдәләрнең 22 пункты нигезендә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуны раслау максатында, тиешле документлар соралган.

Тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясенең яшь гаиләләр өчен торак программаларын гамәлгә ашыру буенча комиссиясенең 2014 елның 15 октябрендәге карары нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгының 2014 елның 28 октябрендәге 1511р номерлы күрсәтмәсе белән А.Ф. Шиһаповның гаиләсе 2011—2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасында катнашучы яшь гаиләләр исемлегеннән ир белән хатынның икесенең дә яше 35 тән арту һәм исәп нормасыннан күбрәк гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителү сәбәпле төшереп калдырылган.

Гражданин А.Ф. Шиһапов фикеренчә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган 2011—2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасының Яшь гаиләләргә торак алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләре (аның тарафыннан дәгъвалана торган норматив хокукый актлар аларны гамәлгә ашыру максатында кабул ителгән) ел саен яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм түләргә сәләтле булуын тикшерүне күздә тотмый, Россия Федерациясе субъектларына ел саен әлеге документлар соратып тикшерү уздыру буенча вәкаләтләр бирми һәм гражданнарны ярдәмче программада катнашучылар исәбеннән төшереп калдыру мөмкинлеген билгеләми. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торучы яшь гаиләне ир белән хатынның берсе 36 яшькә җитүгә исәптән төшереп калдыру, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, шулай ук Татарстан Республикасы Югары судының берничә тапкыр белдерелгән карашына каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.Ф. Шиһапов Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 22 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларын һәм 23 пунктындагы «б» пунктчасын, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы

карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55, 58 (икенче өлеш) һәм 60 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керә торган норматив хокукый актлар категориясенә туры килә, һәм күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 22 пунктындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган беренче, икенче һәм бишенче абзацларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве тикшерелә ала. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керә торган норматив хокукый актлар категориясенә шулай ук туры килә, һәм әлеге Кагыйдәләрнең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве тикшерелә ала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән шул билгеләнгән: Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса. Шуңа бәйле рәвештә гражданин А.Ф. Шиһапов шикаятенә кушып бирелгән 2014 елның 9 июлендәге, 2014 елның 24 октябрендәге һәм 2014 елның 30 октябрендәге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе хатларының күчермәләре мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә норматив хокукый актларның дәгъвалана торган нигезләмәләренең куллануын раслый дип каралырга мөмкин.

Шуның белән гражданин А.Ф. Шиһапов шикаяте Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 22 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларының конституциячеллеген тикшерү өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керә, тиешле мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән шикаять бирү таләпләренә туры килә, һәм анда Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алудан баш тарту өчен нинди дә булса нигезләр юк.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 23 пунктындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган «б» пунктчасы шуны билгели: яшь гаиләне Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру нигезе булып Кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган яшь гаиләгә социаль түләү алуга хокук бирә торган нигезләмәләрнең берсенең юкка чыгуы,

шул исәптән ир белән хатынның берсенең яки тулы булмаган гаиләдәге ата-ананың берсенең 36 яшькә җитүе тора.

Россия Федерациясе Конституция Суды, яшь гаиләне социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлегенә кертү турында Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы тарафыннан карар кабул итү көненә ир белән хатынның һәркайсы 35 яшьтән артмаган булырга тиеш дигән яшь буенча чикләүне гражданнарның конституциячел хокукларын бозу буларак бәяләргә кирәкми дип, берничә тапкыр билгеләп үтте (2010 елның 27 маендагы 738-О-О номерлы, 2010 елның 19 октябрендәге 1333-О-О номерлы билгеләмәләре).

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче тарафыннан ир белән хатынның берсе яки тулы булмаган гаиләдәге ата-ананың берсе 36 яшькә җиткәч, яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыруның һәм социаль түләү алуга хокукны югалтуның нигезле булуы турында куелган мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының карап тикшерү предметы булган иде инде. Татарстан Республикасы Конституция суды 2013 елның 15 июлендәге 7-О билгеләмәсендә күрсәткәнчә, тиешле муниципаль программа кысаларында торак алуга социаль түләүләр бирү өчен кирәкле шарт булган яшьне чикләү турындагы нигезләмә үзенең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган Яшь гаиләләргә торак алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 6 пунктындагы «а» пунктчасы белән беркетелгән нигезләмәгә тәңгәл килә, аның нигезендә ярдәмче программада катнашучы яшь гаиләне планлаштырыла торган елда социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлегенә кертү турында Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы тарафыннан карар кабул итү көненә ир белән хатынның һәркайсының яки тулы булмаган гаиләдәге ата-ананың берсенең яше 35 тән артмый.

Моннан чыгып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәнең конституциячеллеген тикшерү федераль законнардагы әлеге норманың Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен бәяләү дигәнне аңлатыр иде, ә бу Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Шулай итеп, яшь гаиләдәге ир белән хатынның яшьләрен чикләүне билгеләгән дәгъвалана торган нигезләмәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә мөрәҗәгать итүченең шикаяте әлеге өлешендә мөмкин дип таныла алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 42 статьясына, 45 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 51 статьясындагы беренче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче

өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Гражданин А.Ф. Шиһапов шикаятен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 22 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014—2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014—2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пунктындагы беренче, икенче һәм бишенче абзацларының конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга кабул итәргә.

2. Гражданин А.Ф. Шиһапов шикаятен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3094 номерлы карары белән расланган 2014—2015 елларга «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 23 пунктындагы «б» пунктчасының конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алудан баш тартырга, чөнки әлеге өлешендә ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Кабул ителгән карар турында якларга — гражданин А.Ф. Шиһаповка, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына хәбәр итәргә.

5. Әлеге эш буенча докладчы судья итеп Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы А.Р. Шакараевны билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эшне карап тикшерү көнен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне тыңлау чираты тәртибендә билгеләргә.

7. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 7-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Ф.Ш. Галиуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 32 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и статьей 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе**

20 октября 2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Ф.Ш. Галиуллиной,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Ф.Ш. Галиуллина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 32 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и статьей 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе, которыми определяются периоды работы (службы), включаемые в стаж государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка Ф.Ш. Галиуллина с 15 марта 1982 года по 20 октября 1989 года включительно работала на различных выборных должностях в органах Всесоюзного Ленинского Коммунистического Союза Молодежи (далее — ВЛКСМ) Казанского государственного педагогического института и в Бауманском районном комитете ВЛКСМ города Казани. В октябре 1989 года в порядке перевода она была принята на работу в Казанское педагогическое училище № 1 преподавателем. В октябре 2001 года заявительница поступила на государственную гражданскую службу Республики Татарстан (далее — государственная служба) на должность начальника отдела науки, высших и средних специальных учебных заведений Комитета по делам детей и молодежи Министерства по делам молодежи и спорту Республики Татарстан в городе Казани. В январе 2006 года гражданка Ф.Ш. Галиуллина поступила на муниципальную службу в Республике Татарстан (далее — муниципальная служба) в муниципальное учреждение «Комитет по делам детей и молодежи Исполнительного комитета муниципального образования города Казани». С апреля 2014 года по настоящее время является государственным гражданским служащим Республики Татарстан и работает в должности начальника отдела развития среднего профессионального образования в Министерстве образования и науки Республики Татарстан.

Заявительница указывает, что до 31 августа 2007 года период

ее работы в органах ВЛКСМ включался в стаж государственной и муниципальной службы и учитывался при выплате ежемесячной надбавки к должностному окладу за выслугу лет (далее — надбавка за выслугу лет), а также других льгот, предусмотренных законодательством о государственной и муниципальной службе. Однако приказом председателя Комитета по делам детей и молодежи Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 31 августа 2007 года данный период ее работы был исключен из стажа государственной и муниципальной службы. Гражданка Ф.Ш. Галиуллина отмечает, что в результате этого с 1 сентября 2007 года у нее уменьшилась надбавка за выслугу лет с 30 процентов до 20 процентов и сократилась продолжительность ежегодного дополнительного оплачиваемого отпуска. При этом, как она полагает, исключение из стажа государственной и муниципальной службы периода ее работы в органах ВЛКСМ может привести к неправомерному лишению ее права для назначения пенсии за выслугу лет.

В этой связи заявительница обратилась в суд с иском к данному муниципальному учреждению о включении в стаж государственной и муниципальной службы периода ее работы в органах ВЛКСМ. Решением мирового судьи судебного участка № 1 Вахитовского района города Казани от 3 марта 2008 года, оставленным без изменения апелляционным определением Вахитовского районного суда города Казани от 27 мая 2008 года, в удовлетворении ее исковых требований было отказано.

Постановлением Президиума Верховного суда Республики Татарстан от 24 декабря 2008 года указанные судебные решения были отменены, и дело направлено на новое рассмотрение в Вахитовский районный суд города Казани, который решением от 5 марта 2009 года удовлетворил ее исковые требования и обязал муниципальное учреждение «Комитет по делам детей и молодежи Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» включить в стаж государственной и муниципальной службы гражданки Ф.Ш. Галиуллиной период ее работы на выборных должностях в органах ВЛКСМ с 15 марта 1982 года по 20 октября 1989 года.

В последующем гражданка Ф.Ш. Галиуллина обратилась в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан с вопросом о предварительном расчете стажа государственной службы, дающего право на назначение пенсии за выслугу лет. В ответе на ее обращение сообщалось, что период работы в органах ВЛКСМ в стаж государственной и муниципальной службы для назначения пенсии за выслугу лет не может быть включен.

Заявительница указывает, что как пунктом 8, подпунктами «а» и «б» пункта 9 части 1 статьи 32 обжалуемого Закона Республики Татарстан, так и пунктом 9, подпунктами «а» и «б» пункта 10 части 1 статьи 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе установлено, что в стаж (общую продолжительность) государственной и муниципальной службы для назначения пенсии за выслугу лет включаются периоды замещения на постоянной (штатной) основе, в частности, должностей в профсоюзных органах,

определенных данным Законом Республики Татарстан, а также должностей руководителей, специалистов, служащих, выборных должностей в центральных, республиканских, областных и районных (городских) органах КПСС и иных должностей.

Тем самым, по мнению заявительницы, граждане, работавшие в органах ВЛКСМ, оказались в неравном положении перед законом в отличие от граждан, работавших в профессиональных союзах и Коммунистической партии Советского Союза, и это, соответственно, приводит к нарушению ее конституционных прав и свобод.

На основании изложенного заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан признать статью 32 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и статью 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе не соответствующими статьям 27 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 47, 50 (часть первая), 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. Согласно части первой статьи 100 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» правом на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан с жалобой на нарушение конституционных прав и свобод обладают граждане, права и свободы которых нарушены законом Республики Татарстан, нормативными правовыми актами Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан, органов местного самоуправления, и их объединения.

При этом статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» установлено, что жалоба на нарушение законом Республики Татарстан или иным нормативным правовым актом конституционных прав и свобод допустима, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан; закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в суде или ином органе.

Статьей 45 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 125-ЗРТ) определены условия, при которых государственные служащие, замещавшие должности государственной службы Республики Татарстан, имеют право на пенсию за выслугу лет. Одним из таких условий, согласно части 3 данной статьи, является достижение возраста, дающего право на страховую пенсию по старости в соответствии с частью 1 статьи 8 Федерального закона от 28 декабря 2013 года № 400-ФЗ «О страховых пенсиях», либо назначение страховой пенсии по старости досрочно или страховой пенсии по инвалидности. Частью 1 статьи 8 указанного Федерального закона определено, что право на страховую пенсию по старости имеют мужчины, достигшие возраста 60 лет, и женщины, достигшие возраста 55 лет. Аналогичное условие для установления муниципальным служащим пенсии за выслугу лет

определено частью 3 статьи 28 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 125-ЗРТ).

Из приложенных к жалобе документов следует, что заявительница не достигла возраста 55 лет и, следовательно, не соответствует условию, дающему право на пенсию за выслугу лет. Это означает, что положения статьи 32 обжалуемого Закона Республики Татарстан и статьи 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе, определяющие периоды работы (службы), включаемые в стаж государственной и муниципальной службы для назначении пенсии за выслугу лет, в конкретном деле заявительницы не применялись и не подлежат применению в настоящее время, поскольку действие оспариваемых положений в этой части распространяется только на государственных гражданских служащих Республики Татарстан и муниципальных служащих в Республике Татарстан, соответствующих условиям, установленным законодательством, одним из которых является достижение пенсионного возраста. Документов, подтверждающих наличие оснований для назначения страховой пенсии по старости досрочно или страховой пенсии по инвалидности, в материалах дела не представлено.

Таким образом, оспариваемые законодательные положения, связанные с назначением пенсии за выслугу лет, не затрагивают конституционных прав и свобод гражданки Ф.Ш. Галиуллиной, в связи с чем жалоба в этой части не отвечает критериям допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», и на этом основании не может быть принята к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

Относительно доводов заявительницы о неправомерности лишения ее надбавок за выслугу лет, а также других льгот, предусмотренных для государственных гражданских служащих Республики Татарстан и муниципальных служащих в Республике Татарстан, необходимо отметить следующее.

Как видно из представленных правоприменительных документов, свое конституционное право на судебную защиту гражданка Ф.Ш. Галиуллина реализовала в судах общей юрисдикции. По ее делу вынесено правоустанавливающее решение о включении в стаж государственной и муниципальной службы периода работы на выборных должностях в органах ВЛКСМ, на основании которого было возбуждено исполнительное производство в ее пользу. Тем самым право заявительницы на получение надбавок за выслугу лет, а также других льгот, предусмотренных законодательством о государственной и муниципальной службе, нельзя считать нарушенным.

В связи с тем, что оспариваемые положения, примененные в конкретном деле, не нарушают права и свободы заявительницы с учетом фактических обстоятельств, установленных в решениях судов общей юрисдикции, жалоба гражданки Ф.Ш. Галиуллиной в части неправомерности лишения ее надбавок за выслугу лет, а также других льгот, предусмотренных для государственных

гражданских служащих Республики Татарстан и муниципальных служащих в Республике Татарстан, в соответствии с взаимосвязанными положениями пункта 2 части первой статьи 46 и пункта 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» также не является допустимой.

Проверка же законности и обоснованности судебных решений, равно как и оценка правомерности действий (бездействия) и решений должностных лиц правоприменительных органов к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, определенной статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», не относятся.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Ф.Ш. Галиуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 32 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и статьей 29 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе, поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Ф.Ш. Галиуллиной и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 9-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 32 статьясы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
20 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматованың бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт стажына кертелә торган эш (хезмәт) чорларын билгеләгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 32 статьясы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ф.Ш. Галиуллина шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Ф.Ш. Галиуллина 1982 елның 15 мартыннан алып 1989 елның 20 октябренә кадәр Казан дәүләт педагогика институтының Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы (алга таба — ВЛКСМ) органнарында һәм ВЛКСМның Казан шәһәре Бауман район комитетында төрле сайлаулы вазыйфаларда эшләгән. 1989 елның октябрендә күчерү тәртибендә ул 1 номерлы Казан педагогика училищесына укытучы булып эшкә алынган. 2001 елның октябрендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба — дәүләт хезмәте) Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының фән, югары һәм урта махсус уку йортлары бүлеге башлыгы вазыйфасына эшкә урнашкан. 2006 елның гыйнварында гражданка Ф.Ш. Галиуллина Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенә (алга таба — муниципаль хезмәт) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль учреждениесенә эшкә урнашкан. 2014 елның апреленнән

алып бүгенгә кадәр Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре булып тора һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында урта һөнәри белем бирүне үстерү бүлеге башлыгы вазыйфасында эшли.

Мөрәҗәгать итүче 2007 елның 31 августына кадәр аның ВЛКСМ органнарында эшләү чоры дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына кертелгәнен һәм тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә (алга таба — тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә), шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган башка ташламалар түләнеп барганда исәпкә алынганын белдерә. Әмма Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисенең 2007 елның 31 августындагы боерыгы белән аның әлеге чордагы эше дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажыннан чыгарылган. Гражданка Ф.Ш. Галиуллина шуның нәтиҗәсендә 2007 елның 1 сентябреннән аның тиешле еллар эшләгән өчен өстәмәсе 30 проценттан 20 процентка кимегәнен һәм еллык түләүле өстәмә отпускның озынлыгы кыскарганын билгели. Шул ук вакытта, аның фикеренчә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажыннан аның ВЛКСМ органнарында эшләү периодын чыгару аны тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнүгә хокукыннан хаксыз рәвештә мәхрүм итүгә китереп чыгара ала.

Шул сәбәпле шикаять итүче әлеге муниципаль оешмага дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына ВЛКСМ органнарында эшләү чоры кертелү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Казан шәһәре Вахитов районы 1 номерлы суд участогы җәмәгать судьясының 2008 елның 3 мартындагы карары белән, Казан шәһәренең Вахитов район судының 2008 елның 27 маендагы апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылып, аның дәгъва иткән таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Татарстан Республикасы Югары суды Президиумының 2008 елның 24 декабрендәге карары белән күрсәтелгән суд карарлары гамәлдән чыгарылган, һәм эш Казан шәһәре Вахитов район судына яңадан каралырга җибәрелгән, Казан шәһәре Вахитов район суды 2009 елның 5 мартындагы карары белән аның дәгъва иткән таләпләрен канәгатьләндергән һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль учреждениесенә гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына аның 1982 елның 15 мартыннан алып 1989 елның 20 октябренә кадәр ВЛКСМ органнарында сайлаулы вазыйфаларда эшләү чорын кертүне йөкләгән.

Шуннан соң гражданка Ф.Ш. Галиуллина тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүгә хокук бирә торган дәүләт хезмәте стажын алдан исәпләтү мәсьәләсе белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать иткән. Аның мөрәҗәгатенә бирелгән җавапта, ВЛКСМ органнарында эшләү чоры тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына кертелә алмый, дип хәбәр ителгән.

Мөрәҗәгать итүче, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 32 статьясының 1 өлешендәге 8 пункты, 9 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары белән дә, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты, 10 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары белән дә билгеләнгәнчә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына (гомуми дәвамлылыгына) даими (штаттагы) нигездә, атап әйткәндә, әлеге Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән профсоюз органнарындагы вазыйфаларда, шулай ук КПССның үзәк, республика, өлкә һәм район (шәһәр) органнарында җитәкче, белгеч, хезмәткәр вазыйфаларында, сайлаулы вазыйфаларда һәм башка вазыйфаларда эшләү чоры эченә кертелә, дип күрсәтә.

Шуның белән, шикаять итүче фикеренчә, ВЛКСМ органнарында эшләгән гражданнар, профессиональ союзларда һәм Советлар Союзының Коммунистлар партиясендә эшләгән гражданнардан аермалы буларак, закон алдында тигезсез хәлдә калалар, һәм бу, шулай итеп, аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 32 статьясын һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 47, 50 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән шул билгеләнгән: Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса.

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номер-

лы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 45 статьясы белән Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфаларында эшләгән дәүләт хезмәткәрләренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә хокуклы булу шартлары билгеләнгән. Әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 1 өлешенә күрә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җитү, яки вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнү бу шартлардан берсе булып тора. Күрсәтелгән Федераль законның 8 статьясының 1 өлеше белән билгеләнгәнчә, картлык буенча иминият пенсиясенә 60 яшькә җиткән ирләр һәм 55 яшькә җиткән хатын-кызлар хокуклы. Муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен шундый ук шарт Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясының 3 өлеше белән (2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) куелган.

Шикаятькә кушымта итеп бирелгән документлардан аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче ханым 55 яшькә җитмәгән һәм, шулай итеп, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә хокук бирә торган шартка туры килми. Димәк, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажына кертелә торган эш (хезмәт) чорларын билгеләгән дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 32 статьясы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясы нигезләмәләре мөрәҗәгать итүченең конкрет эшендә кулланылмаганнар һәм хәзерге вакытта кулланылырга тиеш түгелләр, чөнки дәгъвалана торган нигезләмәләрнең көче бу өлештә законнар тарафыннан билгеләнгән шартларга туры килә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләргә генә тарала, пенсия яшенә җитү исә бу шартлардан берсе булып тора. Эш материалларында вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнү өчен нигезләр барлыгын исбатлый торган документлар тапшырылмаган.

Шулай итеп, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү белән бәйле дәгъвалана торган закон нигезләмәләре гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның конституциячел хокуклары һәм ирекләренә кагылмыйлар, шул сәбәпле шикаять бу өлештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән билгеләнгән рөхсәт ителүителмәү критерийларына җавап бирми һәм шуның нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга кабул ителә алмый.

Мөрәҗәгать итүченең аны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләр өчен каралган тиешле еллар эшләгән өчен өстәмәләрдән, шулай ук башка ташламалардан мәхрүм итүнең

законсызлыгы турындагы дәлилләренә карата түбәндәгеләрне билгеләп китәргә кирәк.

Тапшырылган хокук куллану документларыннан күренгәнчә, гражданка Ф.Ш. Галиуллина үзенең суд яклавына конституциячел хокукын гомуми юрисдикциядәге судларда гамәлгә ашырган. Аның эше буенча ВЛКСМ органнарының сайлаулы вазыйфаларында эшләү чорын дәүләт һәм муниципаль стажга кертү турында хокук куючы карар чыгарылган, шуның нигезендә аның файдасына башкару эше кузгатылган. Шуның белән мөрәҗәгать итүченең дәүләт һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган тиешле еллар эшләгән өчен өстәмәләр, шулай ук башка ташламалар алуга хокукы бозылган дип санап булмый.

Конкрет бу эштә кулланылган дәгъва ителә торган нигезләмәләр, гомуми юрисдикциядәге судларның карарлары билгеләгән фактик хәлләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүченең хокук һәм ирекләрен бозмаганлыктан, гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның шикаяте аны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләр өчен каралган тиешле еллар эшләгән өчен өстәмәләрдән, шулай ук башка ташламалардан мәхрүм итүнең законсызлыгы өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының үзара бәйле булган 46 статьясының беренче өлешендәге 2 пункты белән 39 статьясының икенче өлешендәге 1 пунктлары нигезләмәләре буенча шулай ук рөхсәт ителми.

Суд карарларының законлылыгын һәм нигезлелеген тикшерү, хокук куллану органнарының вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) һәм карарларының хаклылыгын бәяләү кебек үк, Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясының бишенче өлешенә, 67 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 32 статьясы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ф.Ш. Галиуллинаның шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә

мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Ф.Ш. Галиуллинага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 9-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки М.С. Новиковой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 1.4, а также главой VI Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19 «О предоставлении земельных участков для целей, не связанных со строительством»**

20 октября
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки М.С. Новиковой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка М.С. Новикова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 1.4, а также главой VI Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19 «О предоставлении земельных участков для целей, не связанных со строительством» (далее — Положение).

Оспариваемые заявительницей абзац шестой пункта 1.4 и глава VI вышеуказанного Положения регулируют основания и порядок предоставления земельных участков для иных целей, не связанных со строительством.

Как следует из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка М.С. Новикова полагает, что в соответствии с частью 7 статьи 15 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» у нее, как у инвалида, имеется право на предоставление места для строительства гаража или стоянки для технических и других средств передвижения вне очереди вблизи места жительства с учетом градостроительных норм.

Ссылаясь на нормы данного Федерального закона, заявительница обращалась в Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани и к руководителю Исполнительного комитета муниципального образования города Казани по вопросу предоставления земельного участка для гаража, однако ей было отказано и предложено приобрести его в порядке, предусмотренном Земельным кодексом Российской Федерации, на торгах. Гражданка М.С. Новикова в своей жалобе также отмечает, что ранее действовавшим Положением о порядке предоставления находящихся на территории города Казани земельных участков для целей, не связанных

со строительством, утвержденным решением Казанской городской Думы от 23 августа 2006 года № 49-11, прямо предусматривалось предоставление земельных участков для размещения металлических гаражей лицам, которые имеют нарушение здоровья со стойким расстройством функции организма, обусловленное заболеваниями, последствиями травм и дефектами, приводящими к ограничению жизнедеятельности и вызывающими необходимость социальной защиты (пункт 5.1 главы VI Положения). В настоящее время вышеуказанный нормативный правовой акт утратил силу, а из содержания обжалуемых абзаца шестого пункта 1.4 и главы VI оспариваемого Положения, по ее мнению, не ясно, может ли относиться предоставление земельных участков под гаражи для инвалидов, как это было ранее, к иным целям. Тем самым заявительница считает, что данные положения не отвечают критериям правовой определенности, точности, ясности и недвусмысленности толкования и применения.

На основании изложенного гражданка М.С. Новикова просит признать абзац шестой пункта 1.4, а также главу VI Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19, противоречащими статьям 27 (части первая и вторая), 30 и 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. Оспариваемые гражданкой М.С. Новиковой правовые положения затрагивают сферу земельного законодательства. Из содержания части 2 статьи 31 Земельного кодекса Республики Татарстан следует, что порядок и правила предоставления земельных участков, находящихся в собственности Республики Татарстан или муниципальной собственности, гражданам или юридическим лицам определяются Земельным кодексом Российской Федерации, статьей 34 которого (в редакции, действовавшей до 1 марта 2015 года) была предусмотрена обязанность органов государственной власти и органов местного самоуправления по принятию акта, устанавливающего процедуры и критерии предоставления земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, для целей, не связанных со строительством. Реализуя вышеуказанные нормы федерального законодательства, решением Казанской городской Думы от 23 августа 2006 года № 49-11 было утверждено Положение о порядке предоставления находящихся на территории города Казани земельных участков для целей, не связанных со строительством, в том числе для размещения металлических гаражей, утратившее силу в связи с принятием оспариваемого заявительницей Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19. Вышеуказанное Положение регулирует отношения по предоставлению земельных участков для размещения нестационарных торговых объектов, автостоянок, эксплуатации объекта капитального строительства, размещения парковок, а также для иных целей, не связанных со строитель-

ством. Употребление в оспариваемой норме понятия «для иных целей», являясь оценочным понятием, наполняется содержанием в зависимости от фактических обстоятельств конкретного дела и с учетом толкования этого законодательного термина в правоприменительной практике. Применительно к рассматриваемой правовой ситуации следует отметить, что обжалуемое заявительницей нормативное положение подлежит применению во взаимосвязи с абзацами восьмым и девятым пункта 1.4, а также пунктом 6.1 главы VI данного Положения, устанавливающими исчерпывающий перечень случаев, на которые действие рассматриваемого Положения не распространяется, а именно: предоставление земельных участков для целей садоводства, огородничества, ведения личного подсобного и дачного хозяйства на землях, не входящих в границу населенного пункта, а также из состава садоводческих некоммерческих объединений граждан, предоставление земельных участков для размещения рекламных конструкций и средств наружной информации в г. Казани. Установка металлических гаражей в указанный перечень не входит.

Как неоднократно отмечал Конституционный Суд Российской Федерации, оценка степени определенности содержащихся в законе понятий должна осуществляться исходя не только из самого текста закона и используемых в нем формулировок, но и из их места в системе нормативных предписаний (Постановление от 27 мая 2003 года № 9-П, Определение от 25 ноября 2010 года № 1523-О-О).

Обжалуемые заявительницей положения регулируют отношения по предоставлению земельных участков именно для целей, не связанных со строительством, в то время как Федеральный закон от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации», на который она ссылается в обоснование своих требований, устанавливает, что инвалидам предоставляются места для строительства гаража или стоянки для технических и других средств передвижения вне очереди вблизи места жительства с учетом градостроительных норм (часть 7 статьи 15).

Таким образом, оспариваемые гражданкой М.С. Новиковой положения не могут рассматриваться как форма реализации гарантий, предусмотренных вышеуказанным Федеральным законом, поскольку данные нормативные правовые акты имеют различный предмет регулирования. Тем самым довод заявительницы об отсутствии определенности и ясности в содержании оспариваемых норм является необоснованным.

В то же время Конституционный суд Республики Татарстан обращает внимание на то, что из содержания действующего с 1 марта 2015 года пункта 14 части 2 статьи 39.6 Земельного кодекса Российской Федерации усматривается, что гражданам, имеющим право на первоочередное или внеочередное приобретение земельных участков в соответствии с федеральными законами, законами субъектов Российской Федерации, земельный участок, находящийся в государственной или муниципальной собственности, предоставляется на основании договора аренды без проведения торгов в порядке, предусмотренном статьей 39.14 Земельного ко-

декса Российской Федерации. Однако оценка конституционности указанных правовых норм, равно как и проверка законности и обоснованности отказа заявительнице в предоставлении земельного участка для заявленных ею целей, не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Учитывая вышеизложенное, абзац шестой пункта 1.4, а также глава VI Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19, не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки М.С. Новиковой не является допустимой.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки М.С. Новиковой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 1.4, а также главой VI Положения о порядке предоставления земельных участков для целей, не связанных со строительством, утвержденного решением Казанской городской Думы от 27 декабря 2012 года № 10-19 «О предоставлении земельных участков для целей, не связанных со строительством», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение иных поставленных в ней вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке М.С. Новиковой, в Казанскую городскую Думу, а также в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 10-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацы, шулай ук VI бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикованың шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
20 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка М.С. Новикованың шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьминаның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба — Нигезләмә) 1.4 пунктындагы алтынчы абзацы, шулай ук VI бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикова шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаять итүче дәгъва иткән югарыда күрсәтелгән Нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацы һәм VI бүлеге төзелеш белән бәйле булмаган башка максатлар өчен җир кишәрлекләрен бирү нигезләрен һәм тәртибен җайга салалар.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка М.С. Новикова, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 7 өлеше нигезендә аның, инвалид буларак, шәһәр төзү нормаларын исәпкә алып яшәү урыны янында гараж салу яки техник һәм башка хәрәкәт чараларын куеп тору өчен чиратсыз урын алуга хокукы бар, дип саный.

Әлеге Федераль законның нормаларына таянып, шикаять итүче гараж өчен җир кишәрлеген бирү мәсьәләсе белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә мөрәҗәгать иткән, ләкин аның үтенече кире кагылган һәм аңа ул җир кишәрлеген Россия Федерациясе Җир кодексында каралган тәртиптә торгларда алырга тәкъдим ителгән. Гражданка М.С. Новикова үзенең шикаятендә шулай ук түбәндәгене билгеләп үтә:

элегрәк гамәлдә йөргән Казан шәһәр Думасының 2006 елның 23 августындагы 49-11 номерлы карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда Казан шәһәре территорясендәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмә белән тереклек эшчәнлеген чикләүгә китерә һәм социаль яклауга ихтыяҗ тудыра торган авырулар белән бәйле, имгәнүләр һәм дефектлар нәтиҗәсендә организм функцияләренең дәвамлы бозылуы сәбәпле сәламәтлеге какшаган затларга металл гаражлар урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен бирү турыдан-туры каралган булган (Нигезләмәнең VI бүлегенең 5.1 пункты). Хәзерге вакытта югарыда күрсәтелгән норматив хокукый акт үз көчендә түгел, ә дәгъва ителгән Нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацы һәм VI бүлеге эчтәлегеннән исә, аның фикеренчә, инвалидларга гаражлар өчен җир кишәрлекләрен бирү, элеккечә булган кебек, башка максатларга керә алу-алмавы аңлашылмый. Шуның белән мөрәҗәгать итүче әлеге нигезләмәләр аңлатмаларның һәм кулланунының хокукый билгелелек, төгәллек, ачыклык һәм мәгънә берлеге критерийларына туры килми дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка М.С. Новикова 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацын, шулай ук VI бүлеген Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче һәм икенче өлешләр), 30 һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Гражданка М.С. Новикова тарафыннан дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләр җир законнары өлкәсенә кагыла. Татарстан Республиксы Җир кодексының 31 статьясындагы 2 өлеше эчтәлегеннән күренгәнчә, гражданнарга яки юридик затларга Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен бирү тәртибе һәм кагыйдәләре Россия Федерациясе Җир кодексы белән билгеләнә, аның 34 статьясында (2015 елның 1 мартына кадәр гамәлдә булган редакциясендә) дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен төзелеш белән бәйле булмаган максатларда бирү процедураларын һәм критерийларын билгели торган акт кабул итү бурычы каралган булган. Югарыда күрсәтелгән федераль закон нормаларын гамәлгә ашырып, Казан шәһәр Думасының 2006 елның 23 августындагы 49-11 номерлы карары белән, металл гаражлар урнаштыруны да исәпкә алган, Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда Казан шәһәре территориясендәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмә расланган, ләкин ул мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмә кабул ителү сәбәпле көчен югалткан. Югарыда күрсәтелгән Нигезләмә стационар булмаган сәүдә объектларын, автомобиль куеп тору урыннарын урнаштыру, капиталь төзелеш объектын эксплуатацияләү, парковкаларны урнаш-

тыру, шулай ук төзелеш белән бәйле булмаган башка максатлар өчен җир кишәрлекләрен бирү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала. Дәгъвалана торган нормада, бәяләү төшенчәсе буларак, «башка максатлар өчен» төшенчәсен куллануга конкрет эшнең фактик шартларына карап һәм хокук куллану практикасында бу закон терминының аңлатмасын исәпкә алып мәгънә салына. Карала торган хокукый очракка карата шуны билгеләргә кирәк, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмә әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктындагы сигезенче һәм тугызынчы абзацлары, шулай ук VI бүлегенең 6.1 пункты белән үзара бәйләнештә кулланылырга тиеш, аларда исә карала торган Нигезләмәнең көче таралмаган очракларның тулы исемлеге, атап әйткәндә: торак пункты чикләренә кермәгән җирләрдә бакчачылык һәм яшелчәчелек, хосусый ярдәмче һәм дача хуҗалыклары алып бару максаты белән, шулай ук гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык берләшмәләре составыннан җир кишәрлекләрен бирү, Казан шәһәрендә реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен бирү билгеләнгән. Күрсәтелгән исемлеккә металл гаражлар урнаштыру кертелмәгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләгәнчә, закондагы төшенчәләрнең билгелелек дәрәҗәсен бәяләү законның үзенең текстын һәм анда кулланылган тәгъбирләрне генә түгел, ә аларның норматив күрсәтмәләр системасындагы урыннарын да күздә тотып башкарылырга тиеш (2003 елның 27 маендагы 9-П номерлы Карар, 2010 елның 25 ноябрендәге 1523-О-О номерлы Билгеләмә).

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләр нәкъ менә төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала, ә ул үзенең таләпләрен нигезләү өчен таянган «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон исә инвалидларга шәһәр төзү нормаларын исәпкә алып яшәү урыны янында гараж салу яки техник һәм башка хәрәкәт чараларын куеп тору өчен чиратсыз урын бирелүен билгели (15 статьяның 7 өлеше).

Шулай итеп, гражданка М.С. Новикова тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләр югарыда күрсәтелгән Федераль законда каралган гарантияләрне гамәлгә ашыру формасы буларак карала алмый, чөнки әлеге норматив хокукый актларның җайга салу предметлары төрле. Шуның белән мөрәҗәгать итүченең дәгъвалана торган нормаларның эчтәлегендә билгелелек һәм ачыклык булмавы турындагы дәлиле нигезсез.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды игътибарны түбәндәгегә җәлеп итә: 2015 елның 1 мартыннан гамәлдә булган Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясының 2 өлешендәге 14 пункты эчтәлегеннән күренгәнчә, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлекләрен беренче чиратта яки чиратсыз алуга хокуклары булган гражданнарга дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.14

статьясында каралган тәртиптә аренда шартнамәсе нигезендә торг үткәрмичә бирелә. Ләкин күрсәтелгән хокукый нормаларның конституциячеллеген бәяләү, мөрәҗәгать итүче ханымга ул белдергән максатларда җир кишәрлеге бирүдән баш тартуның законлылыгын һәм нигезлелеген тикшерү кебек үк, Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацының, шулай ук VI бүлегенең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәүләре мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясының беренче өлешенең 2 пункты нигезендә гражданка М.С. Новикованың шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясының икенче өлешендәге 1 пунктына, 46 статьясының беренче өлешендәге 2 пунктына, 66 статьясының бишенче өлешенә, 67 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 10-19 номерлы Казан шәһәр Думасының карары белән расланган Төзелеш белән бәйле булмаган максатларда җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1.4 пунктындагы алтынчы абзацы, шулай ук VI бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикованың шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган башка мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка М.С. Новиковага, Казан шәһәр Думасына, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 10-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки М.С. Новиковой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1.3 Генерального плана муниципального образования города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 28 декабря 2007 года № 23-26**

27 октября
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки М.С. Новиковой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка М.С. Новикова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1.3 Генерального плана муниципального образования города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 28 декабря 2007 года № 23-26 (далее также — Генеральный план). Оспариваемый пункт определяет развитие функциональной структуры использования территории муниципального образования города Казани, в том числе устанавливает понятие и перечень видов функциональных зон, а также основные мероприятия по развитию и реконструкции жилых зон, по развитию и реорганизации производственных зон и по развитию рекреационных зон.

Как следует из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданке М.С. Новиковой было отказано Комитетом земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани в предоставлении земельного участка для ведения подсобного и дачного хозяйства и садоводства. Из ответа исполняющего обязанности председателя данного Комитета следует, что Генеральным планом выделение новых земельных участков для размещения садоводческих, огороднических и дачных некоммерческих объединений граждан на территории муниципального образования города Казани до 2020 года не предусмотрено.

Гражданка М.С. Новикова указывает, что в положениях пункта 3.1.3 Генерального плана содержатся меры по развитию жилого фонда и прочих функциональных зон, но отсутствуют мероприятия по развитию зон для ведения садоводства, огородничества и дачного хозяйства. По ее мнению, это приводит к нарушению положений пункта 1 статьи 13 Федерального закона от 15 апреля 1998 года № 66-ФЗ «О садоводческих, огороднических и дачных некоммерческих объединениях граждан» в части неисполнения органами местного самоуправления обязанности по обеспечению граждан земельными участками для ведения данной деятельности.

На основании изложенного гражданка М.С. Новикова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 3.1.3 Генерального плана муниципального образования города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 28 декабря 2007 года № 23-26, не соответствующим статьям 27 (часть первая), 28 (часть первая и вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Из содержания правовых норм Градостроительного кодекса Российской Федерации следует, что генеральный план является принимаемым на уровне поселений и городских округов документом территориального планирования, под которым понимается планирование развития территорий, направленное на определение назначения территорий исходя из совокупности социальных, экономических, экологических и иных факторов в целях обеспечения при осуществлении градостроительной деятельности безопасности и благоприятных условий жизнедеятельности человека, ограничения негативного воздействия хозяйственной и иной деятельности на окружающую среду и обеспечения охраны и рационального использования природных ресурсов в интересах настоящего и будущего поколений, развития инженерной, транспортной и социальной инфраструктур, обеспечения учета интересов граждан и их объединений, Российской Федерации, субъектов Российской Федерации, муниципальных образований (пункты 2 и 3 статьи 1, часть 1 статьи 9, часть 1 статьи 18).

Тем самым генеральный план является нормативным правовым актом, относящимся к сфере законодательства о градостроительной деятельности, и сам по себе не регламентирует выделение земельных участков для размещения садоводческих, огороднических и дачных некоммерческих объединений. Виды разрешенного использования земельных участков, которые могут учитываться при принятии решений о выделении земельных участков для размещения садоводческих, огороднических и дачных некоммерческих объединений, устанавливаются градостроительными регламентами в пределах границ территориальных зон в соответствии с правилами землепользования и застройки, утверждаемыми нормативными правовыми актами органов местного самоуправления.

Таким образом, обращение гражданки М.С. Новиковой не отвечает требованиям, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», согласно которым жалоба на нарушение законом или иным нормативным правовым актом Республики Татарстан конституционных прав и свобод граждан считается допустимой, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан и если закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в суде или ином органе.

Кроме того, заявительница, утверждая о нарушении своих прав, аргументирует это отсутствием в оспариваемой норме положений, предусматривающих основные мероприятия по развитию зон для ведения садоводства, огородничества и дачного хозяйства и, по существу, предлагает внести целесообразные, с ее точки зрения,

дополнения в Генеральный план, что не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь пунктом 1 части первой статьи 46, частями первой и пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки М.С. Новиковой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1.3 Генерального плана муниципального образования города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 28 декабря 2007 года № 23-26, поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных в ней вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке М.С. Новиковой, в Казанскую городскую Думу и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 11-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**Казан шәһәр Думасының 2007 елның 28 декабрендәге 23-26 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге генераль планының 3.1.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикованың шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
27 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка М.С. Новикованың шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараевның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына Казан шәһәр Думасының 2007 елның 28 декабрендәге 23-26 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге генераль планының (алга таба шулай ук — Генераль план) 3.1.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикова шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъвалана торган пункт Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен куллануның функциональ структурасын үстерүне билгели, шул исәптән функциональ зоналар төрләренең төшенчәсен һәм исемләгән, шулай ук торак зоналарны үстерү һәм яңартып төзү, җитештерү зоналарын үстерү һәм үзгәртеп кору һәм рекреация зоналарын үстерү буенча төп чараларны аныклый.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка М.С. Новикованың ярдәмче һәм дача хуҗалыгы һәм бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирелү үтенече Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты тарафыннан кире кагылган. Әлеге Комитетның рәисе вазыйфаларын башкаручының җавабыннан күренгәнчә, Генераль планда 2020 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен урнаштыру өчен яңа җир кишәрлекләрен бүлеп бирү каралмаган.

Гражданка М.С. Новикова, Генераль планның 3.1.3 пункты нигезләмәләрендә торак фондны һәм башка функциональ зоналарны үстерү чаралары бар, ләкин бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы алып бару зоналарын үстерү чаралары юк, дип күрсәтә. Аның фикеренчә, бу мондый эшчәнлек алып бару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү бурычы үтәлмәү өлешендә 1998

елның 15 апрелендәге 66-ФЗ номерлы «Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре турында» Федераль законның 13 статьясының 1 пунктындагы нигезләмәләрне бозуга китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка М.С. Новикова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәр Думасының 2007 елның 28 декабрендәге 23-26 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге генераль планының 3.1.3 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексының хокукый нормалары эчтәлегеннән аңлашылганча, генераль план җирлекләр һәм шәһәр округлары дәрәҗәсендә территориаль планлаштыру документы булып тора, территориаль планлаштыру дигәннән исә шәһәр төзү эшчәнлеген башкарганда хәвефсезлекне һәм кешенең уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү, әйләнә-тирәгә хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тискәре тәэсирен чикләү һәм хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләреннән чыгып табигать ресурсларын саклауны һәм рациональ файдалануны тәэмин итү, инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максаты белән социаль, икътисади, экологик һәм башка факторларның барчасыннан чыгып территорияләрнең максатларын билгеләүгә юнәлдерелгән территорияләрне үстерүне планлаштыру аңлашыла (1 статьяның 2 һәм 3 пунктлары, 9 статьяның 1 өлеше, 18 статьяның 1 өлеше).

Шуннан чыгып генераль план шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнар өлкәсенә карый торган норматив хокукый акт булып тора һәм үзлегеннән генә коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре өчен җир бирүне тәртипкә салмый. Коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре өчен җир бирү турында карарлар кабул ителгәндә исәпкә алынырга мөмкин булган җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгәнчә куллану төрләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән расланган территория зоналары чикләрендә җирдән файдалану һәм биналар салу кагыйдәләре нигезендә шәһәр төзү регламентлары белән билгеләнә.

Шулай итеп, гражданка М.С. Новикованың мөрәҗәгате «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы билгеләгән таләпләргә җавап бирми, алар нигезендә әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса һәм әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт судта яисә башка органда карау төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акты белән гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуына шикаять бирү мөмкин була.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче, үзенең хокуклары бозылуы турында белдереп, моны дәгъвалана торган нормада бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы алып бару өчен зоналарны үстерү буенча төп чараларны күз уңында тоткан нигезләмәләрнең булмавы белән дәлилли һәм, нигездә, Генераль планга, аның фикеренчә, максатка ярашлы өстәмәләр кертергә тәкъдим итә, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясының беренче өлешендәге 1 пунктына, 66 статьясының беренче һәм бишенче өлешләренә, 67 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Казан шәһәр Думасының 2007 елның 28 декабрендәге 23-26 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге генераль планының 3.1.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка М.С. Новикованың шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә аңарда куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка М.С. Новиковага, Казан шәһәр Думасына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 11-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**о прекращении производства по жалобе гражданки Т.И. Порфирьевой на нарушение ее конституционных прав и свобод Распределением бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан по разделам, подразделам, целевым статьям, группам видов расходов классификации расходов бюджетов на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов (приложение 9), утвержденным Законом Республики Татарстан от 27 ноября 2014 года № 107-ЗРТ «О бюджете Республики Татарстан на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов», а также абзацами девятым и четырнадцатым пункта 3 Положения о порядке расходования средств резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 февраля 2002 года № 64**

27 октября
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании сообщение судьи-докладчика Р.Ф. Гафиятуллина, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Т.И. Порфирьевой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступила жалоба гражданки Т.И. Порфирьевой на нарушение ее конституционных прав и свобод Распределением бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан по разделам, подразделам, целевым статьям, группам видов расходов классификации расходов бюджетов на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов (приложение 9), утвержденным Законом Республики Татарстан от 27 ноября 2014 года № 107-ЗРТ «О бюджете Республики Татарстан на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов», а также абзацами девятым и четырнадцатым пункта 3 Положения о порядке расходования средств резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 февраля 2002 года № 64.

Однако 19 октября 2015 года гражданка Т.И. Порфирьева обратилась в Конституционный суд Республики Татарстан с заявлением об отзыве своей жалобы.

2. В соответствии со статьей 47 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение в Конституционный суд Республики Татарстан может быть отозвано заявителем до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан. В случае отзыва обращения производство по делу прекращается.

Поскольку заявительница отозвала свое обращение до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан, производство по данной жалобе подлежит прекращению.

Исходя из изложенного, руководствуясь статьями 47, 63, частями первой и пятой статьи 66, статьей 72 и частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Производство по жалобе гражданки Т.И. Порфирьевой на нарушение ее конституционных прав и свобод Распределением бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан по разделам, подразделам, целевым статьям, группам видов расходов классификации расходов бюджетов на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов (приложение 9), утвержденным Законом Республики Татарстан от 27 ноября 2014 года № 107-ЗРТ «О бюджете Республики Татарстан на 2015 год и на плановый период 2016 и 2017 годов», а также абзацами девятым и четырнадцатым пункта 3 Положения о порядке расходования средств резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 февраля 2002 года № 64, прекратить в связи с отзывом заявительницей данной жалобы.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Т.И. Порфирьевой.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 12-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү (9 нчы кушымта) белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 14 февралендәге 64 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәнең 3 пунктындагы тугызынчы һәм ундүртенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.И. Порфирьеваның шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

2015 ел
27 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Т.И. Порфирьеваның шикаятен алдан өйрәнгән докладчы судья Р.Ф. Гафиятуллинның мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү (9 нчы кушымта) белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 14 февралендәге 64 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәнең 3 пунктындагы тугызынчы һәм ундүртенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.И. Порфирьевадан шикаять алынды.

Ләкин 2015 елның 19 октябрендә гражданка Т.И. Порфирьева Татарстан Республикасы Конституция судына үзенең шикаятен кире алуы турында гариза белән мөрәҗәгать итте.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

Мөрәҗәгать итүче үзенең мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эш карала башланганчыга кадәр кире алганга күрә, әлеге шикаять буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 72 статьясына һәм 73 статьясының беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү (9 нчы кушымта) белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 14 февралендәге 64 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәнең 3 пунктындагы тугызынчы һәм ундүртенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.И. Порфирьеваның шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүченең әлеге шикаятьне кире алуы сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Т.И. Порфирьевага җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 12-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Х.Ш. Губайдуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод отдельными положениями пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366 «О дальнейших мерах по реализации Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ “О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан” и совершенствованию порядка предоставления жилья в рамках республиканской государственной поддержки», а также Порядком предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке и Порядком определения условий и сроков рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке, утвержденными постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366**

11 декабря
2015 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Х.Ш. Губайдуллиной,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступила жалоба гражданки Х.Ш. Губайдуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод отдельными положениями пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366 «О дальнейших мерах по реализации Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ “О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан” и совершенствованию порядка предоставления жилья в рамках республиканской государственной поддержки», а также Порядком предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке и Порядком определения условий и сроков рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке, утвержденными данным постановлением.

Оспариваемые заявительницей правовые нормы устанавливают нормативы общей площади жилых помещений, предоставляемых с государственной поддержкой, процедуру и условия предоставления указанных жилых помещений, а также определяют условия и сроки рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, дочь заявительницы, действовавшая от своего имени и от имени несовершеннолетнего ребенка, 25 августа 2005 года заключила договор социальной ипотеки с потребительским кооперативом «Строим будущее», действовавшим от имени специализированной организации — некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан». По ито-

гам конкурса 14 октября 2008 года она выиграла квартиру в городе Бавлы Республики Татарстан, общей площадью 55,7 кв. метров, из которых с государственной поддержкой на основании установленного норматива им было предоставлено 42 кв. метра по цене 19000 рублей за кв. метр и сверх норматива 13,7 кв. метров по цене 28500 рублей за кв. метр. После выигрыша в конкурсе квартиры и оформления Протокола участия, выбора и передачи квартиры от 24 февраля 2009 года в учетное дело их семьи были внесены изменения с включением в него 27 апреля 2010 года гражданки Х.Ш. Губайдуллиной. Однако, несмотря на включение ее в состав семьи дочери и в Протокол участия, выбора и передачи квартиры от 24 февраля 2009 года, а также заключения дополнительного соглашения от 12 декабря 2014 года к вышеуказанному договору, перерасчета нормативов (сверхнормативной площади), влекущего изменение стоимости квартиры, произведено не было.

Гражданка Х.Ш. Губайдуллина обратилась в суд с иском к специализированной организации — некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан» о возложении обязанности внести изменения в Протокол участия, выбора и передачи квартиры и произвести перерасчет стоимости жилого помещения. Решением Бавлинского городского суда Республики Татарстан от 24 апреля 2013 года, оставленным без изменения судами вышестоящей инстанции, в удовлетворении иска было отказано.

Заявительница считает, что правом на государственную поддержку в системе социальной ипотеки обладают все лица, заключившие договор социальной ипотеки, независимо от времени присоединения к данному договору и соответственно должен быть произведен перерасчет нормативов.

Таким образом, гражданка Х.Ш. Губайдуллина просит признать отдельные положения пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366 «О дальнейших мерах по реализации Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ “О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан” и совершенствованию порядка предоставления жилья в рамках республиканской государственной поддержки», а также Порядок предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке и Порядок определения условий и сроков рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке, утвержденные постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366, в части, не предусматривающей перерасчета нормативов общей площади жилых помещений в связи с изменением состава семьи граждан, заключивших договор социальной ипотеки и подписавших протокол выбора квартиры, не соответствующими статьям 2, 13, 22, 27, 28 и 29 Конституции Республики Татарстан.

2. В Республике Татарстан отношения, направленные на реализацию конституционного права граждан на жилище, а также на объединение усилий государственных органов, органов местного

самоуправления и организаций всех форм собственности по развитию жилищного строительства и формирование рынка доступного жилья, в том числе в системе социальной ипотеки, урегулированы Законом Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан». В силу указанного Закона Республики Татарстан среди основных требований, предъявляемых к государственной поддержке развития жилищного строительства в системе социальной ипотеки, является принятие соответствующими органами правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки, а также норматива общей площади жилых помещений, предоставляемых на принципах социальной ипотеки, порядок реализации которых устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан (пункты 1 и 2 части 1 и часть 2 статьи 11).

Во исполнение отмеченных законодательных положений принят оспариваемый заявительницей нормативный правовой акт, который подлежит применению в системном единстве с постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15 апреля 2005 года № 190 «Об утверждении Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан» (далее — Правила и порядок), определяющим правила и порядок обращения граждан Российской Федерации, являющихся жителями Республики Татарстан, зарегистрированных по постоянному месту жительства, с заявлением о постановке на учет предоставления жилых помещений в рассрочку в соответствии с основными требованиями, предъявляемыми к государственной поддержке развития жилищного строительства, определенными законодательством (по социальной ипотеке) (пункт 1 Правил и порядка).

Согласно пункту 17 Правил и порядка право на государственную поддержку в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в соответствии с Законом Республики Татарстан «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан» возникает с момента включения семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки, в Реестр специализированной организации — некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан», а право состоять в указанном Реестре специализированной организации сохраняется за заявителем до выбора семьей отдельной квартиры (пункт 18 Правил и порядка).

Данная государственная поддержка предоставляется исходя из нормативов общей площади жилых помещений, установленных пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366. Согласно оспариваемому заявительницей Порядку предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке с момента возникновения у граждан права на такую государственную поддержку они в 90-дневный срок со дня получения уведомления о включении в Реестр специализированной

организации (некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан») обязаны заключить договор социальной ипотеки с некоммерческой организацией «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан» и осуществлять ежемесячные платежи предварительных накоплений в установленном размере (пункт 1.9); предоставление жилья по социальной ипотеке осуществляется в том числе в порядке участия в выборе квартиры (по результатам конкурса) (пункт 1.3).

При этом в силу пункта 2.4 указанного Порядка предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке для участия в конкурсе по выбору квартиры допускаются все граждане, заключившие договор социальной ипотеки. В соответствии с пунктом 2.10 этого Порядка после подтверждения гражданами права на государственную поддержку в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки на момент выбора жилого помещения оформляется протокол выбора квартиры, который является неотъемлемой частью договора социальной ипотеки и удостоверяет право победителя конкурса на заселение и пользование выбранной квартирой.

Тем самым нормативы общей площади жилых помещений, предоставляемых с государственной поддержкой, являются неотъемлемой частью процедуры выбора гражданами своих будущих квартир, поскольку от нормативов зависит распределение объема такой государственной поддержки. Следовательно, оспариваемые положения по своему конституционно-правовому смыслу не допускают произведение перерасчета нормативов общей площади жилых помещений, предоставляемых с государственной поддержкой, после проведения конкурса по выбору квартиры. Иное могло бы создать препятствия для выполнения Государственным жилищным фондом при Президенте Республики Татарстан своих обязательств перед другими победителями конкурса и привести к нарушению их конституционных прав и свобод.

Таким образом, обжалуемые положения в указанном заявительницей аспекте не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение гражданки Х.Ш. Губайдуллиной не является допустимым.

Разрешение же вопроса о законности и обоснованности правоприменительных решений по делу гражданки Х.Ш. Губайдуллиной, в том числе с точки зрения правильности применения правовых норм с учетом фактических обстоятельств, не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46,

частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Х.Ш. Губайдуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод отдельными положениями пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366 «О дальнейших мерах по реализации Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ “О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан” и совершенствованию порядка предоставления жилья в рамках республиканской государственной поддержки», а также Порядком предоставления гражданам жилых помещений по социальной ипотеке и Порядком определения условий и сроков рассрочки платежей граждан для приобретения жилья по социальной ипотеке, утвержденными постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 366, поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. В соответствии с подпунктом 2 пункта 1 статьи 333.40 Налогового кодекса Российской Федерации государственная пошлина, уплаченная гражданкой Х.Ш. Губайдуллиной, подлежит возврату полностью.

3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

4. Копию настоящего Определения направить гражданке Х.Ш. Губайдуллиной и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

5. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 14-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«“Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карарының 4 пунктындагы аерым нигезләмәләре белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибе һәм Социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибе белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинаның шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
11 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинаның шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьминаның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «“Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карарының 4 пунктындагы аерым нигезләмәләре белән, шулай ук әлеге карар белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибе һәм Социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибе белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинадан шикаять алынды.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган хокукый нормалар дәүләт ярдәме белән бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативларын, күрсәтелгән торак урыннарны бирү процедурасын һәм шартларын, шулай ук социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгелиләр.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар

күчермәләреннән аңлашылганча, үз исеменнән һәм балигъ булмаган баласы исеменнән эш иткән мөрәҗәгать итүченең кызы 2005 елның 25 августында махсуслаштырылган оешма — «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы исеменнән эш иткән «Строим будущее» кулланучылар кооперативы белән социаль ипотека шартнамәсе төзегән. Конкурс нәтиҗәләре буенча 2008 елның 14 октябрендә ул Татарстан Республикасы Баулы шәһәрендә гомуми мәйданы 55,7 кв. метр тәшкил иткән фатир откан, аларга билгеләнгән норматив нигезендә дәүләт ярдәме белән кв. метр бәясе 19000 сумнан шуның 42 кв. метры һәм кв. метр бәясе 28500 сумнан нормативтан арткан 13,7 кв. метры бирелгән. Конкурста фатир отылгач һәм 2009 елның 24 февралендәге Катнашу, фатир сайлау һәм тапшыру беркетмәсе төзелгәч, 2010 елның 27 апрелендә алар гаиләсенең исәптә тору төпләмәсенә, гражданка Х.Ш. Гобәйдуллина өстәлеп, үзгәрешләр кертелә. Ләкин аның кызының гаилә составына һәм 2009 елның 24 февралендәге Катнашу, фатир сайлау һәм тапшыру беркетмәсенә кертелүенә, шулай ук югарыда күрсәтелгән шартнамәгә 2014 елның 12 декабрендә өстәмә килешү төзелүенә карамастан, фатир бәясе үзгәрүенә китерә торган нормативларны (нормативтан арткан мәйданны) яңадан исәпләү башкарылмаган.

Гражданка Х.Ш. Гобәйдуллина махсуслаштырылган оешма — «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Катнашу, фатир сайлау һәм тапшыру беркетмәсенә үзгәрешләр кертү һәм торак урын бәясен яңадан исәпләү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Югарырак инстанциядәге судлар тарафыннан үзгәрешсез калдырылган Татарстан Республикасы Баулы шәһәр судының 2013 елның 24 апрелендәге карары белән дәгъваны канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, социаль ипотека системасында дәүләт ярдәменә хокукка, шартнамәгә кушылу вакытына карамастан, социаль ипотека шартнамәсен төзегән барлык затлар ия һәм шуңа күрә нормативлар яңадан исәпләнергә тиеш.

Шулай итеп, гражданка Х.Ш. Гобәйдуллина «“Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карарының 4 пунктындагы аерым нигезләмәләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибен һәм Социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибен социаль ипотека шартнамәсен төзегән һәм фатир сайлау беркетмәсен имзалаган гражданнарның гаилә составлары үзгәрү

сәбәпле торак урыннарның гомуми мәйданы нормативларын яңадан исәпләүне күздә тотмый торган өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 22, 27, 28 һәм 29 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасында гражданнарның торакка булган конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның торак төзелешен үстерү һәм торак сатып алырлык базар формалаштыру буенча эшчәнлекләрен берләштерүгә юнәлдерелгән мөнәсәбәтләр, шул исәптән социаль ипотека системасында, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салынган. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәменә карата куела торган төп таләпләр арасында тиешле органнар тарафыннан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен, шулай ук социаль ипотека принципларында бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативын кабул итү бар, аларны гамәлгә ашыру тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели (11 статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктлар һәм 2 өлеше).

Аталган закон нигезләмәләрен үтәү йөзеннән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив хокукый акт кабул ителгән, ул «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба — Кагыйдәләр һәм тәртип) белән системалы берлектә кулланылырга тиеш, әлеге карар даими яшәү урыны буенча теркәлгән Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының законнар белән (социаль ипотека буенча) билгеләнгән торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәменә куела торган төп таләпләр нигезендә түләүләрне кичектереп тору шартларында торак урыннар бирү исәбенә кую турындагы гариза белән мөрәҗәгать итү кагыйдәләрен һәм тәртибен билгели (Кагыйдәләр һәм тәртипнең 1 пункты).

Кагыйдәләр һәм тәртипнең 17 пункты буенча «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә хокук социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләрне Махсуслаштырылган оешма — «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы реестрына кертү вакытыннан барлыкка килә, ә мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән Махсуслаштырылган оешма реестрында тору хокукы гаилә аерым фатир сайлап алганчыга кадәр саклана (Кагыйдәләр һәм тәртипнең 18 пункты).

Әлеге дәүләт ярдәме 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 4 пункты белән билгеләнгән торак урыннарның гомуми мәйданы нормативларыннан чыгып бирелә. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибе нигезендә гражданнарның шундый дәүләт ярдәменә хокукы барлыкка килгән вакыттан алар Махсуслаштырылган оешма («Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы) реестрына кертелү турында хәбәрнамә алган көннән 90 көн эчендә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы белән социаль ипотека шартнамәсен төзергә һәм билгеләнгән күләмдә алдан тупланучы акчаның айлык түләүләрен гамәлгә ашырырга бурычлы (1.9 пункт); социаль ипотека буенча торак бирү шул исәптән фатир сайлауда катнашу тәртибендә гамәлгә ашырыла (конкурс нәтиҗәләре буенча) (1.3 пункт).

Шул ук вакытта күрсәтелгән Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибенең 2.4 пункты нигезендә фатир сайлау конкурсында катнашу өчен социаль ипотека шартнамәсен төзегән барлык гражданнар кертелә. Әлеге Тәртипнең 2.10 пункты буенча гражданнар торак сайлау моментына социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә хокукларын раслагач, фатир сайлау беркетмәсе төзелә, ул социаль ипотека шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора һәм конкурста җиңүченең сайлап алынган фатирга күчү һәм аннан файдалану хокукын раслый.

Шуның белән дәүләт ярдәме белән бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативлары гражданнарның булачак фатирларын сайлау процедурасының аерылгысыз өлеше булып тора, чөнки шундый дәүләт ярдәме күләмен бүлү нормативларга бәйле. Димәк, дәгъвалана торган нигезләмәләр үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча фатир сайлау конкурсын үткәргәннән соң дәүләт ярдәме белән бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативларын яңадан исәпләүне рөхсәт итмиләр. Башкасы исә Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт торак фонды тарафыннан конкурстагы бүтән җиңүчеләр алдында үз бурычларын үтәүгә киртәләр тудырырга һәм аларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерергә мөмкин булыр иде.

Шулай итеп, дәгъвалана торган нигезләмәләрнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән аспектта Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинаның шикаяте карала алмый.

Гражданка Х.Ш. Гобәйдуллина эше буенча хокук куллану карарларының законлы һәм нигезле булулары турындагы

мәсьәләне чишү, шул исәптән фактагы хәлләрне истә тотып хокук нормаларының дөрес кулланылышы күзлегеннән чыгып, Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясының бишенче өлешенә, 67 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «"Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында" 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карарының 4 пунктындагы аерым нигезләмәләре белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибе һәм Социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибе белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинаның шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.40 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә гражданка Х.Ш. Гобәйдуллина түләгән дәүләт пошлинасы тулысынча кайтарылырга тиеш.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Х.Ш. Гобәйдуллинага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

5. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 14-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

17 декабря
2015 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Гибадуллина на нарушение его конституционных прав и свобод отдельными положениями статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина А.А. Гибадуллина,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступила жалоба гражданина А.А. Гибадуллина на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан о порядке представления документов в избирательные комиссии кандидатами, выдвинутыми в порядке самовыдвижения. Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявитель фактически ставит под сомнение конституционность положений пункта 1.1 части 1 и части 5 статьи 39 указанного Кодекса, из содержания которых следует, что гражданин, выдвинувший свою кандидатуру по одномандатному избирательному округу, представляет в соответствующую окружную избирательную комиссию (или комиссию, на которую возложены полномочия соответствующей окружной комиссии) либо в избирательную комиссию, организующую выборы, соответственно, копию паспорта (отдельных страниц паспорта, определенных Центральной избирательной комиссией Российской Федерации) или документа, заменяющего паспорт гражданина; паспорт или документ, заменяющий паспорт гражданина, предъявляется кандидатом при личном представлении документов в избирательную комиссию, копия паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, изготавливается в избирательной комиссии в присутствии кандидата и заверяется подписью лица, принявшего заявление и прилагаемые к нему документы.

Гражданин А.А. Гибадуллин указывает, что он в порядке самовыдвижения своей кандидатуры в депутаты Совета города Зеленодольска Зеленодольского муниципального района подавал документы в территориальную избирательную комиссию города Зеленодольска, на которую были возложены полномочия окружной избирательной комиссии одномандатного избирательного округа № 25 и одномандатного избирательного округа № 7 по выборам депутатов Совета города Зеленодольска Зеленодольского муниципального района третьего созыва.

Заявитель отмечает, что при подаче документов он попросил изготовить копию своего паспорта в избирательной комиссии и

заверить ее подписью лица, принявшего заявление и прилагаемые к нему документы в порядке, предусмотренном частью 5 статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан. Однако в изготовлении копии ему было отказано и разъяснено, что копия паспорта, в силу пункта 1.1 части 1 статьи 39 данного Кодекса, должна изготавливаться кандидатом самостоятельно.

Гражданин А.А. Гибадуллин полагает, что пункт 1.1 части 1 и часть 5 статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан в их взаимосвязи позволяют в одном случае возлагать обязанность по изготовлению копии паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, на избирательную комиссию, а в другом — требовать представления такой копии от гражданина. Кроме этого, он считает, что во избежание указанной неопределенности пункт 1.1 части 1 статьи 39 оспариваемого Кодекса должен содержать также положения, предусматривающие обязанность избирательной комиссии по изготовлению копии паспорта (отдельных страниц паспорта, определенных Центральной избирательной комиссией Российской Федерации) или документа, заменяющего паспорт гражданина.

На основании изложенного заявитель просит Конституционный суд Республики Татарстан признать отдельные положения статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 45 (части первая и вторая) и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Правовое регулирование отношений, связанных с осуществлением конституционного права на участие в выборах, регламентируется Федеральным законом от 12 июня 2002 года № 67-ФЗ «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», имеющим прямое действие и подлежащим применению на всей территории Российской Федерации (пункты 1 и 2 статьи 1).

В силу подпункта «а» пункта 2.2 статьи 33 указанного Федерального закона к заявлению выдвинутого лица о согласии баллотироваться по соответствующему избирательному округу прилагается копия паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина. При этом данной нормой определено, что законом субъекта Российской Федерации может быть предусмотрено, что паспорт или документ, заменяющий паспорт гражданина, предъявляется кандидатом при личном представлении документов в избирательную комиссию, а копия паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, изготавливается в избирательной комиссии в присутствии кандидата и заверяется подписью лица, принявшего заявление и прилагаемые к нему документы.

На основании приведенных федеральных норм республиканский законодатель установил в статье 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан порядок представления документов в избирательные комиссии кандидатами, выдвинутыми в порядке самовыдвижения, в том числе реализовал дискреционное полномочие в части регламентации в обжалуемой норме процедуры изготовления копии паспорта или документа, заменяющего паспорт

гражданина, в избирательной комиссии в присутствии кандидата и с заверением подписью лица, принявшего заявление и прилагаемые к нему документы.

Предусмотренное пунктом 1.1 части 1 статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан требование о представлении гражданином, выдвинувшим свою кандидатуру, копии паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, находится в неразрывном единстве с положением части 5 данной статьи, определяющим обязанность изготовления такой копии непосредственно в избирательной комиссии в присутствии кандидата. Следовательно, установленное оспариваемыми положениями статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан правовое регулирование принято в соответствии с вышеуказанными нормами Федерального закона от 12 июня 2002 года № 67-ФЗ «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации» и само по себе не допускает возможности иной их трактовки в правоприменительной практике.

Таким образом, обжалуемые положения статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан и не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права и свободы человека и гражданина, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданина А.А. Гибадуллина не является допустимой.

Оценка же правомерности действий (бездействия) правоприменительных органов, равно как и внесение целесообразных, по мнению заявителя, изменений в Избирательный кодекс Республики Татарстан, к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, определенной статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», не относится.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Гибадуллина на нарушение его конституционных прав и свобод отдельными положениями статьи 39 Избирательного кодекса Республики Татарстан, поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, а разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину А.А. Гибадуллину, в Государственный Совет Республики Татарстан и в Центральную избирательную комиссию Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 15-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Гыйбадуллинның шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2015 ел
17 декабрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.А. Гыйбадуллинның шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматованың бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы Сайлау кодексының үз-үзен күрсәтү тәртибендә күрсәтелгән кандидатлар тарафыннан сайлау комиссияләренә документлар тапшыру тәртибе турындагы 39 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Гыйбадуллиннан шикаять алынды. Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче асылда күрсәтелгән Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешенең 1.1 пунктындагы һәм 5 өлешендәге нигезләмәләренең конституциячеллеген шик астына куя, аларның эчтәлегеннән күренгәнчә, бермандатлы сайлау округы буенча үз кандидатурасын күрсәткән граждан тиешле округ сайлау комиссиясенә (яисә тиешле округ комиссиясе вәкаләтләре йөкләнгән комиссиягә) я сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә паспортының (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә гражданның паспортын алмаштыручы документының күчермәсен тапшыра; паспорт яисә гражданның паспортын алмаштыручы документ кандидат тарафыннан сайлау комиссиясенә документларны шәхсән тапшырганда бирелә, паспортның яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсе сайлау комиссиясендә кандидат үзе булганда ясала һәм гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп алган зат имзасы белән таныклана.

Гражданин А.А. Гыйбадуллин күрсәткәнчә, ул өченче чакырылыш Яшел Үзән муниципаль районы Яшел Үзән шәһәре Советы депутатларын сайлау буенча 25 номерлы бермандатлы сайлау округы һәм 7 номерлы бермандатлы сайлау округының округ сайлау комиссиясе вәкаләтләре йөкләнгән Яшел Үзән шәһәре территориаль сайлау комиссиясенә Яшел Үзән муниципаль районы Яшел Үзән шәһәре Советына депутатлыкка үз кандидатурасын күрсәтү тәртибендә документлар тапшырган булган.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, документлар тапшырганда ул Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә үз паспортының күчермәсен сайлау комиссиясендә ясатуны һәм күчермәне гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп алган зат имзасы белән таныклауны сораган. Ләкин күчермә ясаудан аңа баш тартылган һәм паспорт күчермәсе әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешенең 1.1 пункты нигезендә кандидат тарафыннан мөстәкыйль ясатылырга тиеш дип аңлатылган.

Гражданин А.А. Гыйбадуллин фикеренчә, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының үзара бәйләнештә 39 статьясындагы 1 өлешенең 1.1 пункты һәм 5 өлеше бер очракта паспорт яки гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсен ясау бурычын сайлау комиссиясенә йөкләргә, ә икенче очракта андый күчермәне гражданның үзеннән таләп итәргә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, күрсәтелгән билгесезлектән котылыр өчен, ул дәгъвалана торган Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешенең 1.1 пунктында сайлау комиссиясенең паспортның (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсен ясау бурычын күздә тота торган нигезләмәләр булырга тиеш дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 45 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Сайлауларда катнашуга конституциячел хокукны гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон белән регламентлана, ул турыдан-туры гамәлдә һәм Россия Федерациясенең бөтен территориясендә кулланылырга тиеш (1 статьяның 1 һәм 2 пунктлары).

Күрсәтелгән Федераль законның 33 статьясындагы 2.2 пунктының «а» пунктчасы нигезендә күрсәтелгән затның тиешле сайлау округы буенча сайланырга ризалык бирүе турындагы гаризасына паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документының күчермәсе теркәлә. Шул ук вакытта әлеге нормада Россия Федерациясе субъекты законы белән паспорт яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның кандидат тарафыннан сайлау комиссиясенә документларны шәхсән тапшырганда бирелүе, ә паспортның яисә гражданның паспортын алмаштыручы документ күчермәсенең сайлау комиссиясендә кандидат үзе булганда ясалуы һәм гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп алган зат имзасы белән таныклануы каралган булырга мөмкин дип билгеләнә.

Китерелгән федераль нормалар нигезендә республика закон

чыгаручысы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясында үз-үзен күрсәтү тәртибендә күрсәтелгән кандидатлар тарафыннан сайлау комиссияләренә документлар тапшыру тәртибен билгеләгән, шул исәптән дәгъвалана торган нормада паспортның яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсен сайлау комиссиясендә кандидат үзе булганда ясау һәм күчермәне гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп алган зат имзасы белән таныклау процедурасын регламентлаштыру өлешендә дискрецион вәкаләтләрен гамәлгә ашырган.

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 1 өлешенең 1.1 пункты белән каралган үз кандидатурасын күрсәткән граждан тарафыннан паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документының күчермәсен тапшыру турындагы таләп әлеге статьяның андый күчермәне турыдан-туры сайлау комиссиясендә кандидат үзе булганда ясау бурычын билгели торган 5 өлешендәге нигезләмә белән аерылгысыз берлектә. Димәк, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы дәгъвалана торган нигезләмәләре белән билгеләнгән хокукый җайга салу «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның югарыда күрсәтелгән нормалары нигезендә кабул ителгән һәм үзеннән-үзе хокук куллану практикасында аларны бүтән төрле аңлату мөмкинлегенә рөхсәт бирми.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы дәгъвалана торган нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм алар кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп санала алмый, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданин А.А. Гыйбадуллинның шикаяте карала алмый.

Хокук куллану органнары гамәлләренең (гамәл кылмавының) хаклылыгын бәяләү, Татарстан Республикасы Сайлау кодексына мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр кертү кебек үк, Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясының бишенче өлешенә, 67 статьясының беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

